АЛ ДА ГӨЛ ТҮГЕЛ

Телләр комиссиясе милли мәгариф проблемаларын чишү юлларын эзләде

> 2

ГӨРЛӘП ЯШӘҮ

«ВТ» журналистлары Мамадыш районында булып кайтты

> 3

ТӨЗӘЛМӘС ЯРА

Разил Вәлиевнең «милләт» дип янган йөрәге тибүдән туктады

> 6

ТОРМЫШ, ИСӘНМЕ!

Саҗидә Сөләйманова исемендәге премиянең быелгы лауреатлары – кемнәр алар?

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 155–156 (29122–29123) | Сишәмбе | 24 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Җәйге ял сагындырырга да өлгермәде, көзге каникул чоры җитте. Әти-әниләргә дә, балаларга да, кыска вакытка гына булса да, шатлык, әлбәттә. SuperJob хезмәте мәгълүматына ышансаң, көзен отпуск алып, ял итәргә җыенган россиялеләр саны 38 процентны тәшкил итә. Чит илләргә һәм Россиянең төп шәһәрләренә агылучы туристлар елның бу фасылында да шактый. Көзге ялны ничек уздырырга?

Эшле ял

Быел балаларның ялы 30 октябрьдә башланып, 5 ноябрьдә тәгәлләнәчәк. Әлмәттә яшәүче биш бала әнисе Рәдифә Ногманова, көзге каникул чорында балаларны каядыр җибәрергә ниятләмим, ди.

– Олы балабыз 9 нчы сыйныфта укый, көн дә мәктәптә «электив»ка йөриячәк. Кечкенәләре әле бакчада, – ди күпбалалы әни. – Элегрәк, башлангыч сыйныфта укыганда, калабыздагы сәламәтләндерү учреждениеләрендә укучылар өчен көзге лагерьлар була торган иде. Түләү әллә ни зур булмагач, баргаладылар. Соңгы елларда бу хезмәт тә кыйммәтләнде, шуңа барганыбыз юк.

Ишле гаиләдә өй тирәсендә эш һәрвакыт булып тора. Шуңа күрә бала-чагага нишләргә икән дип баш ватасы юк. Рәдифә ханым да шундый фикердә.

– Безнең өйдә эшнең бетәсе юк. Беренчедән, ял вакытында балаларны йокылары туйганчы йоклату яклы мин. Аннан соң көн саен өйне җыештырырга, ишегалдында вак-төяк эшләр булып тора. Кыскасы, эш терапиясе белән ял итәчәкләр, – ди ул. – Теләкләре булганда, дуслары яисә класслары белән киногa барып кайтырлар. Атна-ун көн вакыт уза да китә инде ул.

Читтәге кояш тансык

Казанда яшәүче Салават белән Эльвина узган атнадан башлап Дубайда ял итәләр. Отпуск дигәнен календарьга карап сайламый яшь гаилә. Икесенең дә өч ел читтә ял иткәне булмаган: хатыны бала табып, аны тәрбияләсә, гаилә башлыгы эшләгән дә эшләгән.

– Җәен кояш тансык түгел лә ул. Шуңа Казанда көннәр суыткач, үзебезгә ял оештырырбыз дип хәл иткән идек. Төркиядә булганыбыз бар иде, шуңа Дубайны сайладык, кесәгә бәрә торган як булса да, безгә ошый, – ди Салават. – Баланы әбиләре һәм минем олы апам карый. Сабыйның әле ел әйләнәсе ял, шуңа ул әти-әнисен ял иттерә *(көлә)*. Мәктәптә укый башлагач, аның каникулына тәгаенләп ял ала торган итәрбез.

Көзге ялны ничек уздырырга?

Бу сорауны Казан экскурсоводлары гильдиясе әгъзасы, Татарстанда кунакчыллык илчесе Раушания Миңнуллинага бирдек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТАНСЫК ЯЛ

– Көзге чорда балаларга һәм әти-әниләргә кая барырга, нәрсә карарга? Бу, әлбәттә, музейлар. Алар туристларны каршы алырга һәрвакыт әзер. Айның һәр беренче сишәмбесендә музейларга керү бушлай икәнен дә истә тотыйк. Әмма каникул чорында алай булырмы икән, монысын урында белешергә кирәк, – диде экскурсовод. – Бик күп остаханәләр эшли. Әйтик, «Туган авылым» комплексында. Хан һәм ханбикә булып киенеп, фотога төшәргә дә мөмкин әле. Шәһәрдән чыгып китсәк, Тукай юллары буйлап Кырлайга, Зөя, Болгарга барырга мөмкин. Мин әле тагын кунача Лениногорск – Шөгергә барырга тәкъдим итәм. Нефтьне чыгара башлауның юбилей елын исәпкә алсак, музеена керергә була. Ул бик шәп. Лениногорскига барышлый Алексеевскига керергә була, анда борынгы туку станоклары бар. Чистайда яңа төр форматта экскурсияләр уза. Әлмәттә кунып, музыка үзәгенә сугылырга мөмкин. Тарихи Бөгелмәне дә урап узмасыннар иде. Сабадагы Миңгәргә барырга, көнне картинг-клубта уздырырга мөмкин. Татарстаныбызның теге ягына чыгып, Кама Тамагына игътибар итсәк, андагы штольня, виноград, сыр җитештерү урыннарына керергә мөмкин. Иделнең суы китте бит инде, беләсез. «Идел төбенә» дигән экскурсияләр үткәрәләр хәзер. Анда юл түшәүдә кулланылган иске булыжниклар калкып чыкты. Халык элеккеге Мәскәү тракты нинди булган, шуны карый. Казан шәһәрендәге паркларга, Милли китапханәдәге «МОÑ» мәйданчыгына игътибар итәргә була. Глэмпинглар турында барыбыз да беләинде. Туризм буенча дәүләт комитеты сайтына кереп, кесәгә дә, күңелгә дә яраклы юнәлешләрне барларга мөмкин.

Ата-аналарның ялы һәрвакыт баланың каникулы белән тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Сүз дә юк, балаларын мәктәп яны лагерьларына, махсус сменаларга, әби-бабай янына җибәрүчеләр булыр. Әмма көн дәвамында эштә булып, баланың барыр урыны һәм мөмкинлеге булмаган очракта нишләргә?

Баланың фантазиясен үстерү өчен, аңа **иҗади эш** йөкләп калдырырга мөмкин. Әйтик, квест уйлап тапсын. Бу мантыйк, күзәтү, фикер йөртү кебек сыйфатларны үстерергә булышачак. Квестны исә соңрак гаилә белән сынап карарга да мөмкин.

Куллары белән нидер эшләргә яраткан балага **коллаж** яисә **«хыял картасы»** ясарга тәкъдим итәргә була.

Әти-әнинең дә ял көннәре булмый калмый. Эштән иртәрәк кайткан очраклар да юк түгел. Андый вакытта бергәләп кино-театрга, фотосессиягә бару йә булмаса **уртак хобби** табу мөһим. Әйтик, бергәләшеп алма пирогы пешерү, китап уку, бәйләү яисә тегү.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Йөзгә берәү тулмаган

«Безнең ишегалды» республика программасы 99 процентка үтәлгән. Аны 33 районда төгәлләгәннәр.

«Татарстанда шәһәрләрне үстерү институты» фонды директоры Наилә Зиннәтуллина әйтүенчә, ел башыннан бирле республикада яшәүчеләрдән ишегалларын тәртипкә салуга бәйле 7,1 мең мөрәҗәгать кергән. Шуның 131е – соңгы атналарда. Мөрәҗәгатьләрдә асылда ишегалды юлында су җыелып тору, подъезд ишеге түбәсеннән су тамып тору кебек мәсьәләләр күтәрелгән.

Наилә Зиннәтуллина сүзләренә караганда, программа нигезендә башкарылачак эшләр буенча халык белән очрашулар үткәрелә. Киләсе елда үзләренең ишегаллары төзекләндерелүен зарыгып көтүчеләр белән очрашуларның 90 проценты узган инде. Аксубай, Баулы, Югары Ослан, Алабуга, Яшел Үзән, Кукмара, Балык Бистәсе, Сарман районнарында шундый очрашулар үткәрелгән.

Иң түбән дәрәҗәдә

Быел гыйнвардан августка кадәрге чорда Татарстанда үлем-китем күрсәткече Идел буе федераль округы төбәкләре арасында иң түбән дәрәҗәдә теркәлгән. Росстат мәгълүматлары буенча, күрсәткеч 1000 кешегә 10,7 очрак тәшкил иткән. Узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда республика күрсәткече 6,1 процентка кимегән. Узган елның гыйнвар – август айларында исә 1000 кешегә 11,4 очрак туры килгән.

2023 елның гыйнварыннан августка кадәр округның Киров һәм Пенза өлкәләрендә үлүчеләр саны барыннан да күбрәк теркәлгән. Аларның һәркайсында үлем-китем коэффициенты 1000 кешегә 14,9 очрак тәшкил иткән. Гомумән алганда, быел гыйнвардан августка кадәрге чорда округта 1000 кешегә 13 кеше үлгән. Үлем-китемнәр узган елның шушы ук чорындагы белән чагыштырганда 6,5 процентка кимегән.

Урынын тапканнар

Ана капиталы гамәлгә кертелгәннән бирле Татарстанда 404 меңнән артыграк сертификат бирелгән. Россия Социаль фондының Татарстандагы идарәчесе Эдуард Вафин әйтүенчә, республикада яшәүчеләр акчаның иң күп өлешен торак шартларын яхшыртуга тоткан.

Гомумән, барлыгы 358 мең гаилә дәүләт ярдәмен урнаштырган инде. Аларга җәмгысы 133,65 миллиард сумнан артыграк акча күчерелгән. 300 мең гаилә фатир сатып алуга 127,6 миллиард сум юллаган. Тагын 40,3 мең гаилә балаларына белем бирүгә 1,9 миллиард сум акча тоткан. Ә инде 170тән артыграк хатын-кыз булачак пенсияләренең тупланма өлешенә 50 миллион сум акча җибәргән. 17 мең гаилә ана капиталыннан балаларына айлык түләүгә барлыгы 1,4 миллиард сум алган.

Хәвефсез юл

Үзе генә сакламый

Тиздән машинадагы бала кәнәфиенә булган таләпләр катгыйланырга мөмкин. Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин хәрәкәт иминлеге буенча хөкүмәт комиссиясенә шундый күрсәтмә биргән. Россия Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы 15 ноябрьгә кадәр проектны эшләп бетерергә тиеш.

Юллардагы вазгыятьтән чыгып ясалган тәкъдим бу. Рәсми саннардан күренгәнчә, гыйнвар – сентябрь аралыгында Россия юлларында балалар катнашында 13,5 мең юл һәлакәте килеп чыккан. Бу, алдагы ел белән чагыштырганда, 10 процентка күбрәк. Ел башыннан бирле теркәлгән шундый юл һәлакәтләренең 910ында балалар махсус кәнәфидә утырмаган яки куркынычсызлык каешы эләктерелмәгән булган.

Белгечләр юл һәлакәтләрендә зыян күргән балалар саны артуның тагын бер сәбәбен атый. Соңгы арада ата-ана баланы машинага утыртканда махсус кәнәфи урынына каешка тагыла торган өчпочмак формасындагы чүпрәк җайланма гына куллана башлаган. Шуны таксаң, каеш шумый, баланың гәүдәсе төз тора, күкрәк читлеге дә каплаулы була, янәсе. Махсус кәнәфи белән чагыштырганда арзанрак та. Бүген ул уртача 200–500 сум тора. Өстәвенә аны инде без ияләнеп өлгергән маркетплейслардан да җайлы гына сатып алып була.

Әмма белгечләр чаң суга! Әлеге чүпрәк җайланма махсус кәнәфине һич кенә дә алыштыра алмый. «НАМИ» фәнни-тикшеренү үзәге белгечләре бу уңайдан уздырылган махсус тикшеренү барышында мондый ялган саклагыч чараларның, киресенчә, бала сәламәтлегенә зыян гына салуын ачыклаган.

– Машинада утырган бала шушы өчпочмаклы җайланма тагылган каеш ярдәмендә генә эләктерелгән булса, юл һәлакәте вакытында ул аның астыннан шуып чыгачак яки буылып калачак. Чүпрәк букчаны хәтерләткән каркассыз кәнәфиләр дә куркыныч. Алар юл һәлакәте вакытында баланы тотып кала алмый, – ди үзәк белгече Денис Загарин.

Бу юлларны язганда, нигездә, маркетплейсларда сатылучы мондый ялган саклагыч җайланмалар белән якыннанрак танышып чыгасы иттек. Баксаң, товар турында тулы мәгълүмат язылган бүлектә акка кара белән «бу җиһаз мөстәкыйль рәвештә генә баланы саклап бетерә алмый, ул махсус кәнәфи белән бергә генә кулланылырга тиеш» дип язылган. Бу искәрмәгә колак салу-салмау инде һәркемнең үзеннән тора. Әмма бала гомере турында сүз барганда мондый кисәтүне колак аша уздыруның башка сыймаслык хәл икәнлеге көн кебек ачык. Шуңа күрә белгечләр мондый кисәтүләргә игътибар итмичә, машинага баласын юк-бар саклагыч җайланма ярдәмендә генә утырткан ата-анага штраф сала башларга тәкъдим итә дә инде.

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Дәүләт Думасы Рәисе:

Бизнес белән шөгыльләнүчеләргә тынычлап эшләргә ирек бирергә кирәк. МВД вәкилләре исә игътибарын иҗтимагый куркынычсызлыкны саклауга, җинаятьчелеккә юнәлтсен иде. Президент әйткән йөкләмәләрне үтәп, бу өлкәләрне контрольдә тотыгыз.

(Парламент тыңлауларыннан)

РОССИЯДӘ – ФӘННИ-ТЕХНИК ҮСЕШ

РИА «Новости» мәгълүмат агентлыгы белгечләре Россия төбәкләренә фәнни-техник үсеш буенча бәя биргән. Рейтингның беренче урынында Мәскәү булса, соңгы урында – Ингушетия Республикасы.

2022 елдагы урыны	Төбәк	Рейтинг баллы	2021 елдагы урыны
1	Мәскәү	79,66	1
2	Санкт-Петербург	72,58	2
3	**Татарстан**	**68,03**	**3**
4	Түбән Новгород өлкәсе	64,27	4
...			
85	Ингушетия Республикасы	8,13	85

Бозлавык һәм юеш кар

Бу атнада юеш кар, урыны белән буран, бозлавык, һава температурасының төшүе көтелә. Чәршәмбе – 25 октябрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы +1...–4 күрсәтәчәк. Төнге сәгатьләрдә температура –2...–7 градуска кадәр төшәчәк. Төньяктан секундына 7–12 метр, урыны белән 15–18 метр тизлектә җил. Юлларда бозлавык булырга мөмкин.

Моңа кадәр КФУ метеорология, климатология һәм атмосфера экологиясе кафедрасы доценты Тимур Әүхәдиев әйтүенчә, октябрьнең соңгы көннәрендә Казанда беренче кар төшәчәк. Ә инде 17 ноябрь тирәсендә җиргә кар ятачак.

vk.com

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ПЛАНЕТА ЯЗМЫШЫ ХӘЛ ИТЕЛГӘНДӘ

Дөньяда сәяси киеренкелек үзенең югары ноктасына омтыла. Аның асыл сәбәпләре финанс кризисының тирәнәюенә бәйле. АКШта бюджет дефициты 2023 финанс елында 1,7 триллион долларга җитте. Бу алдагы елдагыдан 300 миллиард долларга күбрәк. Бюджет керемнәре 9,3 процентка кимегән. Дәүләт әҗәтенең масштабы да рекордлы. Байден шул сәбәпле «яңа дөнья тәртибе» дип шаулый да инде. Аның фикеренчә, якындагы 4–5 елда алдагы 40–50 еллык тормышны билгеләячәк вакыйгалар булып узачак.

Американнарның максаты ачык: Якын Көнчыгышны коллыкка төшереп (хәтта анда яшәүчеләрне юк итеп), үзләренең матди мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү. Төбәккә гадәттән тыш зур Америка, Англия, Франция гаскәрләре китерелде. Грециядәге хәрби базаларга гына да 60 F-35 самолеты тупланды.

Газзә фаҗигасе бөтен ислам дөньясында зур сызлану һәм көчле реакция тудырды. Үткән атна ахырында төрек лидеры Әрдоганның аркадашы, идарә итүче коалициягә кергән партия лидеры Дәүләт Бахчәли, Израиль 24 сәгать эчендә Газзәне бомбага тотудан туктамаса, Төркия тыкшынырга тиеш, дип белдерде. Ультиматумның срогы чыкты инде. Шактый зур көчкә ия булган мөселман илләренең лидерлары, чынлап та, Газзәгә гуманитар ярдәм күрсәтү генә түгел, тынычлык урнаштыручы мөселман хәрби көчләрен төзү турында да сүз кузгатты. Якшәмбедә Әрдоган Малайзия Премьер-министры Ибраһим белән Вахдеттин сараенда ябык режимда очрашты. Рәсми төрек газетасы Yeni Şafak: «Фәләстыйнның иминлеген тәэмин итәрлек көч төзергә вакыт җитте», – дип яза. Газета фикеренчә, Төркия, Пакьстан, Мисыр, Согуд Гарәбстаны кебек дәүләтләр Фәләстыйн белән чиктәш илләрдә уртак үз хәрби көчләрен җәелдерергә тиеш. АКШ исә Фәләстыйнны якларга теләгән дәүләтләргә һәм мөселман төркемнәренә ут ачарга вәгъдә итә. Вазгыять бик киеренке, чынлыкта бар Җир шарының язмышын хәл итәчәк вакыйгалар формалашып ята. Норвегиянең тышкы эшләр министры Эспен Барт Эйде: «Кризис дөньякүләм масштабтагы кризиска әйләнү белән яный», – диде.

Күпчелек Европа илләрендә Фәләстыйнны яклап демонстрацияләр үткәрү тыелган булса да, Франция, Англия, Германия, Дания һәм башка дәүләтләрдә сиончылар вәхшилегенә каршы урамнар тулган протест акцияләре оешты. Аларда: «Елгадан алып диңгезгә кадәр Фәләстыйн азат булачак», – дигән лозунглар күтәрелде. АКШта сиончыларга каршы гыйбриләр Капитолий үрендәге Вәкиллекләр палатасының офис бинасына бәреп керде һәм Газзәдәге геноцидны туктатуны таләп иттеләр.

Фәләстыйн кризисы фонында алтын бәясе унциягә 2 мең доллардан артып китте. АКШның финанс министры Йеллен: «Ике сугышка көчебез җитә», – дип белдерде.

Россиядә

БӘЯ ТӨШКӘЧ, КЕМГӘ ФАЙДА?

Россиядә дә дөньякүләм кризисның билгеләре торган саен күбрәк сизелә. Әмма безне икътисадның процент капиталына нигезләнгән моделенә соңрак калып кушылуыбыз һәм гадәттән тыш бай ил булуыбыз коткара.

Инфляция төп проблемаларның берсе булып калуын дәвам итә. Үзәк банк аналитиклары, инфляциянең быелгы фаразланган күләмен 7 процентка җиткерү кирәк, диләр. Бәяләр тотрыклылыгының әлегә хыял гына булып калуын Үзәк банкның бу атнада төп ставканы янә күтәрергә җыенуы да дәлилли. «Российская газета»ның дүшәмбе санында «Банк России почти наверняка поднимет ключевую ставку на следующей неделе» дигән язма ярылып ята. Төп ставка 14 процент булыр, диләр. Инфляция 7 генә процент булса, төп ставканы алай ук күтәрмиләр. Димәк, 7 дип әйтәбез, тагын кимендә 7не уйда тотабыз. Кредитлы икътисад өчен инфляциядән бигрәк, дефляция куркыныч. Германиядә әнә бәяләр котырып түбәнгә төшә башлаган. Җитештерүчеләр бәясе индексы 14,7 процентка төшкән. Мондый хәл 1949 елдан соң беренче тапкыр икән. Иң эре сәүдә челтәрләре азык-төлеккә бәяләрне 5–25 процентка кадәр түбәнәйткәннәр. Кулланучылар өчен бәя төшү сөенеч булса да, капитализм өчен чынлап та бәла ул дефляция: беренчедән, халык кулында акча юклыкны аңлата, икенчедән, эшсезлек чәчәк атуына ишарә итә, өченчедән, бәя төшкәч, кешеләр кредит алудан туктый.

Россиягә әле тиз генә андый куркыныч янамый. Көнбатышта бәяләр төшү чимал урнаштыруны проблемага әйләндерә. Санкцияләр килеп кушылгач, эш тагын да кыенлаша. Газга санкцияләр кертелмәде, әмма аны сату авыр. Кытайга визит вакытында «Себер көче – 2» торбасы турында килешүгә ирешелмәде. Сәясәтчеләр Европага саткан газны Кытайга озату турында фанфаралар какса да, тармак белгечләре моның реаль түгеллеген әйтә. Алдагы елларда газны геосәясәт коралы итеп файдалану тискәре нәтиҗәләр бирә. Пекинның Мәскәү саткан чималга бәйлелеккә төшәсе килми. Киләчәктә Мәскәүдә, кытайлар туңа, дип сөенеп утырмаслар дип кем гарантия бирә ала? Шуңа күрә Кытайда Казахстан белән яңа газ күләмнәре турында килешү төзиләр, Мәскәүне өметләндерәләр генә.

Торба газы урынына сыеклаңдырылган газ сатуга өметләр дә акланмый. Аны җитештерү һәм экспортлау да беренче яртыеллыкта 5–10 процентка кимегән.

ҮЗЕБЕЗДӘН ТОРА



tatarstan.ru

Рәсми Татарстан

Республика районнарында салым җыю эше аксый. Бу уңайдан Татарсан Рәисе Рөстәм Миңнеханов мәсьәләгә кичекмәстән ачыклык кертергә кушты. «Кара исемлек»кә кайсы районнар эләккәне дә билгеле.

Татарстан Министрлар Кабинетында 2023 елның тугыз аенда Татарстанның берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм ел азагына кадәр бурычлар буенча финанс, казначылык һәм салым органнарының эшенә багышланган республика киңәшмәсе узды. Аны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үткәрде.

– Бу елның гыйнвар – сентябрь айларында Татарстанның берләштерелгән бюджетына 395,5 миллиард сум акча кергән. Республиканың үз керемнәре 331,2 миллиард сум тәшкил иткән, – диде Рәис, төп саннарга тукталып. – Безгә тынычланырга иртәрәк. Хәзерге шартларда вазгыять бик тиз үзгәрергә мөмкин. Шуңа күрә финанс тәртипне катгый үтәүне дәвам иттерергә кирәк.

Татарстан финанс министры Радик Гайзатуллин әйтүенчә, бюджет үтәлешен тәэмин итүдә табышка салым мөһим урын алып тора. Быелның тугыз аенда республика казнасына табышка салымнан 133,2 миллиард сум акча кергән. Физик затларның керемена салым исә 93,1 миллиард сум тәшкил иткән.

Киңәшмәдә билгеле булганча, Татарстанның ике районында – Яңа Чишмә һәм Апаста физик затларның керемена салым кимегән. Ә җир салымын киметүгә юл куючылар исемлегенә республиканың берьюлы 33 районы эләккән. Шул ук вакытта, быел нефть һәм газ комплексы, нефть сәнәгате предприятиеләрендә табышка салым күрсәткече сизелерлек кимүен дә искәрттеләр. Бу уңайдан, Рәис предприятиеләрдә вазгыятьне даими күзәтеп торырга, җитештерүчеләр белән берлектә финанс күрсәткечләренә анализ ясарга кушты. Республиканың Икътисад, Финанс министрлыкларына, шулай ук салым хезмәтенә бергәләп эшне җайга салырга кирәк, дип белдерде Рөстәм Миңнеханов. Чөнки бюджетның сыйфатлы һәм тигез үтәлеше бик күп күрсәткечләргә бәйле.

Физик затларның керемена салымга килгәндә, Рәис «соры» хезмәт хакларына каршы көрәшне дәвам иттерергә кирәк дигән фикердә. Ул быел салым җыюларын киметкән районнар белән дә аерым эшләргә кирәклеген искәртте.

– Узган ел белән чагыштырганда, җир салымы тугыз процентка, ягъни 530 миллион сумга кимегән. Бу – бик зур сан. Республиканың 33 районында күрсәткечләр тискәре. Әлеге районнарның барысын да атап тормыйм, әмма мәсьәләгә ачыклык кертеп, тиешле чараларны күрегез, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстанда яшәүчеләргә 1 декабрьгә кадәр салымнарны түләп бетерергә кирәклеген дә искә төшерделәр. Салым федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе җитәкчесе Марат Сафиуллин сүзләренә караганда, республика халкына 3 миллиард 225 миллион сумлык 500 салым хаты җибәргәннәр.

– Дәүләт һәм муниципаль органнарга, федераль хезмәтләргә һәм предприятиеләргә аңлату эшләре алып барырга, 2022 ел өчен милек салымын вакытында түләп бетерүне, шулай ук булган бурычларны кайтаруны тәэмин итәргә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Судан юл туры

Ил буенча сәяхәт итәргә теләүчеләргә яңа юл салдылар. Казанга Түбән Новгородтан Идел буйлап «Метеор» килде. Ике шәһәр арасында соңгы утыз елда тәүге пассажир рейсы бу. Казаннан су буйлап тагын кайларга сәяхәт итеп була? Елга маршрутларын «ВТ» хәбәрчесе белеште.

– Ил буйлап сәяхәт итәргә яратам. Түбән Новгородтан Казанга «Метеор» йөри башлаячагын белгәч, билетны махсус сатып алдым, – дип сөйләде Татарстан башкаласына тәүге маршрутта йөзеп килгән Олег Николаев. – Мин Ярославльдә яшим. Казанга тәүге сәфәрем түгел. Шәһәр бик ошый. Өйгә шул ук юл белән кайтып китәргә ниятлим.

Су юлыннан Казан белән Түбән Новгород арасы сигез сәгатькә якын вакыт тәшкил итә. Әлеге маршрутта Козьмодемьянск һәм Чабаксар шәһәрләрендә ике тукталыш та каралган. Бер яктан икенчесенә кадәр билет бәясе 2500 сум тора.

«Татарстан флоты» генераль директоры Роман Лизалин сүзләренә караганда, «Бөек Идел юлы» проекты кысасында Идел буенда урнашкан барлык төбәкләрдә дә елга транспортында хәрәкәтне үстерү каралган.

– Әлеге эш белән шөгыльләнүче оешмаларга бәйле рәвештә, программа берничә өлешкә бүленгән. Мәсәлән, Татарстан, Чуашстан, Түбән Новгородның үз судносары бар. Без үзара кем кайсы юнәлештә хәрәкәт итәчәген билгеләдек, – дип сөйләде ул.

Идел буендагы шәһәрләрнең үзара көндәш түгеллеген дә искәртте Роман Лизалин. Хәер, тел төбендә хикмәт тә бардыр. Быелның сентябрендә генә яңа судноны суга төшергән Түбән Новгород оешмасы, навигация чоры инде тәмамланып килүгә дә карамастан, Казанга юл салып куйды әнә. Яңа маршрут халык теленә керә торсын, диделәр, ахры.

Билгеле булганча, «Татарстан флоты» акционерлык җәмгыяте быелның маенда оешты. Җәй башында Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов оешмага Яшел Үзән заводында төзелгән ике судноны кулланышка тапшырды. Республика җитәкчесе тармакны үстерү бурычын да куйды.

– Бу елның августында Казан белән Ульяновск арасында даими рейслар ачылды, – диде Роман Лизалин. – Сентябрьдә Алабугадан Сарапулга тәҗрибә рәвешендәге рейс оештырылды. Октябрь башында исә Казаннан Чабаксарга су юлы салынды.

«Татарстан флоты» генераль директоры әйтүенчә, су юлы маршрутлары бик тә отышлы.

– Казаннан Ульяновск шәһәренә поездда – биш, машинада өч сәгатьтә барып җитәргә мөмкин. Ә су транспорты ярдәмендә ике шәһәр арасы 3 сәгать тә 40 минут тәшкил итә. Аның каравы табигатькә хозурланып, уңайлы шартларда барасың. Әлеге маршрутны киләсе елда тагын да үстерәчәкбез. Моннан тыш, Уфага рейслар җибәрүне сорап мөрәҗәгать иттеләр, – диде Лизалин.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Сан

Татарстанның эчке су юллары озынлыгы 1 мең чакрымнан артык.

ЧИРНЕ ЯШЕРМИК

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНДА МИЛЛИ МӘГАРИФ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШТЕЛӘР

И туган тел!

Милли мәгариф ни хәлдә? Милли кадрларны кем әзерләргә тиеш? Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов җитәкли торган комиссия утырышы бу юлы әнә шул мәсьәләләргә багышланган иде. Чарада яңгыраган төп фикерләр – безнең язмада.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Утырыш алдыннан Марат Әхмәтов комиссия ярдәмендә гамәлгә ашырылган милли проектлар белән танышты. «ВТ» да үз проектларын күрсәтте.

Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе утырышында ике һәм аннан да күбрәк телле мәктәпләрне укытучылар белән тәэмин итү турында сөйләштеләр. Милли мәгариф системасында еллар дәвамында җыелып килгән проблемалар күп. Утырыш әнә шул фикердән башланды.

– Әйтик, узган гасырның 70–80 нче елларында төзелгән мәктәп-бакчалар 1990 нчы еллардагы милли күтәрелеш чорында үз эшчәнлегенә милли эчтәлек өстәде. Кызганыч, 2000 нче еллар дәвамында ул кимеде. Нинди үзгәрешләр барганы һәрберебезнең күз алдында бит. 2000 нче еллардан соң төзелгән мәгариф оешмалары исә белем һәм тәрбияне күбесенчә рус телендә бирә. Бүген без балалар һәм әти-әниләрнең милли мәгариф учреждениеләренә карата кызыксынуын арттырырга тиеш. Эчтәлек ягыннан да, эчке җиһазландыру ягыннан да. Моның өчен урыннарга чыгарга, кимчелекле якларны табып, аларны хәл итәргә кирәк, – диде комиссия җитәкчесе Марат Әхмәтов.

Билгеле, комиссия рәисе утырыш буе кимчелекле өлкәләр турында гына сөйләмәде. Уңай яклар да бар. Бу җәһәттән район һәм шәһәр хакимиятләренең милли мәсьәләләргә карата игътибарын арттыруын, туган телләр буенча мәктәп олимпиадаларында катнашучыларның саны күп булуын, чыгарылыш сыйныф укучыларының туган телләр буенча имтихан тапшыруын мисал итеп китерде ул.

– Узган уку елында 9 нчы сыйныфны тәмамлаган 2502 укучы туган телләрдән имтихан тапшырды. 2362се – татар, 99ы – чуаш, 12се – мари теленнән. Татарстан Республикасында яшәп, туган теленнән дәүләт имтиханын тапшырган балаларны да, аларның ата-аналарын да күтәреп йөртергә кирәк, – диде Марат Әхмәтов.

Ике, өч, дүрт…

Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллинның саннарга бай чыгышыннан менә нәрсә аңладык: бүген республикада 77 мең укытучы исәпләнә, шуларның нибары 3,3 меңе генә – туган тел укытучысы. Мәктәпләрдә фәннәрне туган телдә укытучы мөгаллимнәр саны – 14 мең. Милли мәгариф өлкәсендәге проблемаларны хәл итүнең бер юлы – ике һәм аннан күбрәк телдә укыта алырлык укытучылар әзерләү. Утырышның темасына килеп җиттек, кыскасы.

Арча педагогика көллиятенә укырга кергән студентлар, мәсәлән, килеп керүгә, ике телле мохиткә эләгә. Әлеге уку йортының җитәкчесе шулай диде. Ике-өч телле кадрлар әзерләүнең үз методикасы да бар икән.

– Бездә Татарстанның 20 районы һәм шәһәреннән һәм 12 төбәктән 930 студент белем ала. 1 курска кабул иткәндә, без аларның белемнәренә анализ ясыйбыз. Икенче этапта исә булган базаны камилләштерү өстендә эшлибез. Шуннан студентлар милли сыйныфларда практика уза. Дүртенче этапта исә студент берничә телдә укытырга өйрәнә, – дип, бәйнә-бәйнә сөйләде Гөлнара Гарипова. Арча көллиятендә укып чыгучыларның 94 процентының эшкә урнашуын да искәртте ул.

Билгеле, көллиятләрдә югары уку йортларындагы кадәр санда милли белгечләр әзерли алмыйлар. Әмма булган санны арттырырга кирәк – утырышта яңгыраган чираттагы фикер шул булды.

Өйдәме, мәктәптәме?

Күптән бара торган бәхәс тагын телгә алынды. Туган телне кем өйрәтергә тиеш – гаиләме, мәктәпме? Ике төрле фикер яңгырады.

– Туган телне сакларга ниндидер закон проектлары ярдәм итәчәгенә ышану – ахмаклык. Дәреслекләр алуга зур-зур суммалар тотылса да, мәктәпләрдә туган телләр укытылса да… Бала үз гаиләсендә туган телен ишетми икән, бу тырышлык бушка булачак, – диде Гөлнара Гарипова.

– Тел проблемасын гаилә дә хәл итә алмый. Милли мәгариф, телебезне саклау – фәннәрне ана телендә укыта торган милли мәктәпләр кулында, – диде Татарстанның халык укытучысы, комиссия әгъзасы Камәрия Хәмидуллина.

Чынбарлык

Билгеле, укытучылар турында сүз чыккач, аларга түләнә торган хезмәт хакының түбән булуы да телгә алынды. Марат Әхмәтов бу мәсьәләдә федераль дәрәҗәдәге карарлар кирәклеген искәртте.

– Ә без, үз чиратыбызда, мөмкин кадәр кызыксындыру чаралары өстәү турында уйлашырбыз, – диде ул.

Милли мәгариф системасына килгәндә, ни генә булса да, безгә чынбарлыкны ачыкларга кирәк. Утырыш ахырында әнә шундый нәтиҗә ясалды.

– Безгә, һичшиксез, милли мәктәпләрнең эшчәнлеген өйрәнергә кирәк. Чыгып кычкырып сөйләшү өчен түгел, алар үзләренең кем икәнлеген белсен өчен. Ничек кенә булса да, чирне яшермичә, чынбарлыкны ачыкларга кирәк, – диде Марат Әхмәтов.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

«ВТ» – кунакта

МАМАДЫШ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ АНАТОЛИЙ ИВАНОВ:

«ТАШ ТА ҮСӘ, ҖИР ҮСМИ»

Күпләр бәхет эзләп читкә киткән җиреннән кире Мамадышка әйләнеп кайта. Биредә яшьләрне туган якларында калдыру юлларын эзлиләр, яшәү өчен уңайлы шартлар тудырырга тырышалар. Туристлар җәлеп итү өчен дә зур эшләр башкарыла. Мамадышның уңыш сере нидә соң? «ВТ» журналистлары район башлыгы Анатолий ИВАНОВ белән шул хакта сөйләште.

:: Анатолий Петрович, Мамадышта туристларны җәлеп итү буенча күп эшләнелә. Татарстанда кече шәһәрләр арасында беренчеләрдән булып елга ярлары төзекләндерелде, ял итү урыннары булдырыла. Районга кунаклар чакыру үзен аклыймы?

– Туристлар килсен дип тырышу үзен аклый ул. Районга килгән һәр кеше безгә акчасын калдырып китә бит. Шуңа да алар кабат килсен өчен уңайлы шартлар тудыру мөһим. Аларны ашатырга, йокларга кирәк. Димәк, үзеннән-үзе кунакханәләргә, кафе-рестораннарга ихтыяҗ туа. Бүген барча районнар да туристларны җәлеп итәргә тырыша. Шул исәптән без дә яңадан-яңа уй-хыяллар белән яшибез. Кешеләрнең күңеленә хуш килерлек ял итү төрләрен барлыйбыз. Кайберләрен үзебездә булдыру өчен тырышабыз. Киләсе елның ноябрь аенда Түбән Камага күпер ачылыр дип көтәбез. Шуннан соң Мамадыш белән Түбән Кама арасын 30 минутта үтеп булачак. Күпер ачылгач, Әлмәт, Зәй районнары халкы да безгә йөри башлар дип торабыз. Мамадыш бит таулар, урманнар арасында урнашкан. Экологик яктан чиста урында утыра.

«Нократ» яр буенда өч күл бар. Анда тонна ярым балык җибәрдек. Кил дә тотып ал. Яр буеннан ерак түгел балалар мәйданчыгы урнаштырылды. Анда аттракционнар эшләп тора. Күптән түгел бирегә җылытыла торган пляж ясадык. Анда көймәләр, катамараннарда да йөреп килү мөмкинлеге бар. Ул комплекста төрле мунчалар, тоз бүлмәләре эшли. Монда ял итүнең бер сәгате – 200 сум. Су мотоцикллары куймакчы булабыз. Кешеләр бирегә яратып йөри. Килүчеләрнең 70 проценты – туристлар.

:: Туристларны кунак итү өчен үз эшен белүче персонал кирәк. Аларны ничек әзерлисез?

– Әлегә килгән туристлар белән музей хезмәткәрләре эшли. Әлбәттә, әгәр туризм тагын да җәелеп китсә, безнең районга агылучылар арта икән, без махсус белгечләр әзерләячәкбез. Мондый кал булыр да инде ул. Эшлисе килгән эшләр күп. Язын Нократ елгасына туристлар белән 6–7 теплоход керә. Алар безне узып китеп, Кировка кадәр баралар. Бу маршрут бар кешегә дә ошый. Туктап-туктап ял итәләр. Әмма бер проблема бар – су кими. Хәзер менә шул юнәлештә эшлибез.

Максатыбыз – Мамадышка килгән кеше аның бөтен матурлыгын күреп, яңы теләгән җирдә ял итеп китсен иде. Безнең шәһәрнең икенче башында ипподром бар. 1 гыйнварга кадәр шул якта тау шуу базасы ачарга җыенабыз. Әлегә башта атларда йөрергә, аннан картингка керергә була. Анысы да шул мәйданда урнашкан. Биредә 24 гектарга сузылган ылыслы урман бар. Без шәһәр эчендә шуның хәтле агачны саклап кала алдык. Анда ачык урында тимераякта шуу өчен каток ясадык. Әле менә шунда ук йога үзәге дә төзеп ятабыз. Димәк, туристлар бер көндә генә китә алмаячак бездән. Шартлары шәһәрдәгечә булса да, бәяләре «тешләмәячәк».

Тиздән «Регина» ял комплексында зоопарк та булачак. Казаннныкы кадәр үк булмаса да, балалар өчен шактый кызыклы булыр дип уйлыйбыз. 20 глэмпинг урыны ясала. Инде хәзер үк биредә 200 кешелек кунакханә эшли. Әле монда республикада тиңе булмаган канат юлы да ачылачак. Нократның бер ягыннан икенче ягына канат юлы белән чыгып булачак, каршы як яр буенда кафелар төзеләчәк, чистартылган пляж булачак.

Быел без беренче тапкыр һава шарлары фестивале уздырдык. Искиткеч матур чара булды ул. Катнашырга теләүчеләр бик күп иде. Киләсе елда май аеннан августка кадәр атна саен фестиваль уздыру нияте бар.

:: Мамадыш зур шәһәрләр белән янәшә урнашкан. Андагы сәнәгать оешмалары районның эшче кулларын үзенә алмыймы? Районда кадрлар мәсьәләсен ничек хәл итәсез?

– Бүген бездә эш яшендәге 19 мең кеше бар. Шуның 14 меңе районда хезмәт куя. 5 мең кеше бездә теркәлгән булса да, төрле шәһәрләргә китеп эшләп йөри. 700 кешебез Алабуга икътисадый зонасында эшли. Анда китүчеләр 100әр мең сум хезмәт хакы ала. Китеп эшләүчеләрнең уңай ягын эзлибез – алар бездә яши, акчасын монда тота, салымын түли. Көндәшлек туа, читкә киткән кешеләрне кире кайтару өчен бездә эшләүче оешмалар хезмәт хакларын күтәрергә мәҗбүр була. Димәк, районда яшәүче кеше күп акча ала башлаячак. Бу – кешеләрнең тормыш шарты яхшыру дигән сүз.

Берничә елдан Мамадышта шактый завод-фабрикалар ачылачак. КАМАЗ заводы җир алып, үз эшен башлаячак. Картон фабрикасы ачылырга тора. Чәчәк үстерү теплицасы, торбалар ясаучы һәм башка бик юнәлештә эшләүче җитештерү заводлары ачылачак. Безгә инвесторларны җәлеп итү кыен түгел. Район олы юл буенда урнашкан. Транспорт чишелеше уңайлы.

:: Анатолий Петрович, сез – үз районын күтәргән, аның киләчәге өчен күп эш башкарган җитәкче. Шунда туып, гомер буе шунда яшәгәнсез. Сезнең өчен Мамадыш нәрсә ул?

– Август аенда хезмәт юлын башлап җибәргәнемә 45 ел тулды. Барлык эш урыннарым районга бәйле. Мин башка җирдә болай эшли дә алмас идем. Үз ягым, үз якташларым өчен дип эшлим. Мин җитәкче түгел, мондагы гади бер кеше булып яшәдем. Минем өчен гадилек – беренче урында. Син бүген – түрә, иртәгә – пенсиядәге кеше. Картлыгыңда хөрмәтле булыр өчен, кешеләрне аңлап эшләргә кирәк. Мин кайда гына эшләсәм дә, холкым үзгәрмәде. Башлыкны югары күтәрмәдем. Ишегемдә халыкны кабул итү сәгате дә, көне дә язылмаган. Без – тәүлек әйләнәсе халык белән эшләргә тиешле кешеләр. Шуңа күрә миңа әйтер сүзе булган кеше теләсә кайсы вакытта кабинетыма керә ала.

:: Нинди гаиләдә үстегез?

– Әтием мәктәп директоры иде. 40 яшендә атказанган укытучы исеме алган кеше ул. Ул заманда ук мәктәптә акча эшли белгән. Алмагач бакчасы утыртып, җиләкләр үстереп саткан. Шул акчага спорт залы, ашханә төзеткән. Авыр гаиләдәге балаларны киендергән. Укучыларны бушка ашаткан. Әни 43 ел башлангыч сыйныфларда балалар укытты. Биш бала идек без. Инде өчебез генә исән. Армиядән соң Ярославльгә укырга киттем. Шунда әнидән хат килде. Биш бала үстерел, без ялгыз калдыкмыни, дигән. Шул сүз җитә калды миңа. Ул чакта дүрт туганым Украинада яши иде. Аларны, «КамАЗ» машинасына прицеп тагып, Мамадышка күчендердем. Бишебез дә монда гомер иттек. Керәшен авылында туып, марилар янына укырга йөрдем. Урыслар белән бергә яшәдем. Миңа бар милләт тә якын. Татулыкның сере дә – бер-беребезнең динен, гореф-гадәтен хөрмәтләүдә.

:: Мамадышның үсеш ноктасын нидә күрәсез?

– Районда сәнәгать мәйданчыклары төзеп калуыбызга сөенеп туя алмыйм. Алар – районның киләчәге. Район үссен, алга таба атласын өчен, иң элек яхшы хезмәт хакы түләрлек эш урыннары булдыру кирәк. Икенчедән – кешеләрне тораклы итү мөһим. Өченчедән – инфраструктура булсын. Балалар өчен барлык шартлар тудырылсын. Хәзерге вакытта хезмәт хакларын тагын да күтәрү буенча эшлибез. Йортлар төзелеп тора.

Авылларны саклар өчен җиргә якынаерга кирәк. Россиядә эшкәртелмичә ятучы 45 миллион гектар җир бар. Әнә шуларны барлап, тиешле кулларга тапшырасы иде. Таш та үсә, җир үсми. Шулкадәр байлыкны әрәм итмәскә иде. Кайсы гына өлкәне алма, эшлим, диючегә мөмкинлек бирергә кирәк. Әйтик, урман хуҗалыгы. Бездә агачлар черел ята, ә аны кисеп алырга рөхсәт юк. Хәтта урманчылыкдар да моны эшли алмый. Эшкәрт тә сат, әрәм итмә бит! Шулай ук бездә җиңел сәнәгатьне үстерү җитми. Әнә Кытайда эш башлаучыга процентсыз кредит бирәләр. Әле моннан 40 ел элек алар хәерчелектә иде. Ә хәзер безне 100 елга узып киттеләр. Өйрән тегәргә, шартлар тудыр. Тегә белмәсән, сүтеп карап өйрән. Аяк киемен дә тегәр идек, күлмәген дә... Пошлинасы зур, кәгазь эше, тикшеручесе күп. Шуларны тәртипкә салсак, безгә читкә йөрергә дә кирәкми. Үзебез дә булдырабыз бит. Әнә читтән товарлар кертелми башлау үз җитештерүчеләребезгә юл ачты.

Без Татарстанда яшәвебез белән бәхетле. Рәисебез Рөстәм Миңнеханов көн-төн эшли, аннан күреп без дә тик тормыйбыз. Дәүләт программалары җитәрлек. Иренмичә эшләргә генә кирәк.

Түбән Ушма

Әлеге авыл үзенә җәлеп итеп тора. Район үзәгеннән дә ерак түгел, авылның бар матурлыгын, хисен, ямен дә саклап калган. Матур табигатьле, бер гасырдан артык тарихы булган мәчетле, кешеләрне ашлы да, эшле дә иткән Түбән Ушма безне пыскак яңгыр белән каршы алды.

ЭШЛЕ ДӘ, АШЛЫ ДА АВЫЛ

tatarstan.ru

Тау башыннан төшкәндә бик матур булып җәелеп ята Түбән Ушма. Тирә-якта тәртип, чисталык. Бакча артында ук урман шаулый. Авыл уртасыннан Ушма елгасы ага. Йортлары нык, матур, арада икешәр катлысы да бар. Авыл эчендә мәктәп, балалар бакчасы, мәчет, кибетләр эшләп тора. Шунысы күңелле: урамда балалар чыр-чуы ишетелә.

Шәһәрдән – авылга

Авыл башында ук Мамадыш эшмәкәре, «Продпрограмма» авыл хуҗалыгы оешмасының генераль директоры Рифат Мотыйгуллинның фермалары урнашкан. Иң элек шунда туктадык. Оешманың хезмәткәрләр белән эшләү буенча директоры Илшат Шәйдуллин – әле монда яңа кеше. 9 ел Түбән Ушма авылы мәктәбен җитәкләгәннән соң, эш алыштырган. Авылының чын патриоты икәнлеге күренеп тора. Авыл тарихын да белә, инде менә яңа эшендә дә байтак нәрсәгә өйрәнгән. Ул безне иң элек «Продпрограмма»ның Түбән Ушмадагы бүлеге белән таныштырды. Оешмада барлыгы 30 мең баш мал бар. Түбән Ушмада 2300 сыер савалар. Савучылар сменалап эшли. Таләпләр катгый, маллар янына кертмәделәр. Сөтлебикәләрне читтән гена күзәтеп, бирегә 2014 елдан бирле хезмәт куючы Рамил Нургалиев белән сөйләшәбез. Рамил – Казан егете. Шәһәр шау-шуыннан туеп, Түбән Ушмага кайтып китүенә хәзер сөенеп бетә алмый.

– Авиатөзелеш районының 10 нчы татар гимназиясендә укыдым. Әнием бу авылныкы. Җәйләрен кунакка кайтып йөрдем. Шунда булачак хатыным белән таныштым. Гаилә корып җибәрдек. Казанда яши башладык. Әмма күңелгә нидер җитми иде. Шәһәрдән качасы килде. Хатыным белән киңәшләштек тә Түбән Ушмага кайтып төпләндек. Өй салып кердек. Өч бала үстерәбез, – дип сөйли Рамил.

Әлеге хатыны декрет ялында. Ул да «Продпрограмма»ның Малмыжка фермасында хезмәт куя икән.

– Шәһәрдә яшәргә җитәрлек хезмәт хакы алабыз. Өч балабыз булгач, акчаның артыгы юк. Аларны шәһәргә җибәреп укытасы бар бит. Киләчәкләрен уйлыйбыз. Әмма без аларны укытып, монда кайтару яклы. Шәһәрдә бик тынгысыз. Әни янына кунакка барганда да, тавыштан туеп кайтып китәм. Анда машиналар тавышы, кешеләре кәефсез. Монда җәен сандугачлар сайрап уята, һавасы чиста, кешесе ярдәмчел. Җаныма тынычлык тапкан урын бу, – ди Рамил.

Илшат Шәйдуллин машинасына утырып, авыл эченә үтәбез. Вакытны әрәм итмибез, әлеге дә баягы Илшат эшләгән оешма турында сөйләшәбез. Юл буенда очраган алма бакчасы да аларныкы икән. Моннан биш ел элек Рифат Мотыйгуллин утырткан булган. Инде дүрт ел уңыш алып торалар. Алманы эшчеләргә төшке ашка өләшәләр, пешекчеләр компот, кайнатма ясыйлар икән.

– Безгә әллә кайлардан килеп эшлиләр: Оренбург, Можга, Башкортстан, Мәскәү, Чаллы, Казаннан... Иртән Алабугадан бер егет эшкә килде. Килеп эшләүчеләр өчен тулай торак бар. Авыл эчендәгесендә 68 кеше яши. Әле Мамадышта 30 урынлы кунакханә белән 15 йорт, 8 таунхаус бар. Гаиләләре белән бездә эшләүчеләргә йорт та салып бирәбез. Алар аны ипотекага ала. Кыйммәт чыкмый ул. Кайбер кешеләр ул акчаны эшләп түли. Хезмәт хакыннан тотып баруны сизми дә кала, – ди Илшат. – Безгә авыл хуҗалыгы юнәлешендәге югары уку йортларыннан студентлар практикага кайта. Аларга да акча түлибез. Күбесе укып бетергәч, кире эшкә килә. Яшьләр эштән курыкмый. Аларга күп акча һәм яшәү өчен уңайлы шартлар кирәк. Әллә кайлардан килеп тә, Мамадышта яшәп калучы бар. Иң мөһиме – тормышы канәгатьләнерлек булсын!

123 еллык мәчет

Авыл эченә үтәбез. Илшат безне иң элек мәчеткә алып китте. Тау битендә урнашкан иман йорты авыл өстенә нур сибә кебек. Бик матур итеп төзекләндерелгән. Монысы да – авылдашлары Рифат Мотыйгуллин эше.

Безне Илнар хәзрәт Фәхретдинов каршы алды. Районда манарасы киселмичә калган бердәнбер мәчет бу. 123 еллык тарихы бар.

– 1898 елны иске мәчеттә янгын чыга. Шуннан соң авыл картлары Казан сәүдәгәре Әхмәт Хөсәеновка мәчет төзүне сорап мөрәҗәгать итә. Ул каршы килми. Шуннан соң яше-карты эшкә тотына. Яңа мәчет 1904 елда сигез манаралы булып төзелеп бетә, – дип сөйли Илнар хәзрәт. – Тege заманнарда манараның бишесен кисәләр, өчесе утырып кала. Манара кискән вакытта көчле давыл чыга. Шуннан соң кисүчеләр авылдан китеп бара.

2006 елда шул чакта хуҗалык рәисе булган Рафаэль Мөхәммәтшин иман йортын тулысынча төзекләндерә. Өч ел элек Рифат Мотыйгуллин янә мәчетне яңарта, ремонт ясала. Җомга намазына мәчеткә 65 кеше йөри икән. Бәйрәмнәрдә халык сыймыйча, урамга чыга. Бирегә балаларга кечкенәдән дин сабаклары бирәләр. Һәр җомга иртән мәктәптә әхлак дәресләре укытыла.

«Телне саклар өчен өйдә бары тик татарча сөйләшергә кирәк. Телне, милләтне, гореф-гадәтләрне бары тик тәрбия белән генә саклап калып була. Нинди генә программалар булмасын, гаиләдә ул юк икән, бернинди уңышка ирешеп булмый. Әгәр милләт һәм гореф-гадәт сакланса, дин дә югалмый», – ди Илнар хәзрәт.

«Тырышмасаң, оят булыр»

Түбән Ушма мәктәбе шул авылда 30 елдан артык хуҗалык рәисе булып торган Мөхәммәтҗан Шакиров исемен йөртә. Ул республикада алдынгы мәктәпләр исемендә йөри. Белем нәтиҗәләре дә, тәрбия эшләре дә сөендерерлек. Бирегә 98 бала белем ала. Сигезе 16 чакрым ераклыктагы Югары Ушма авылыннан килеп укый. Балалар бакчасына 55 бала йөри. Безне яңа гына директор итеп билгеләнгән, моңарчы уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары булып эшләгән Зәйтүнә Шакирова каршы алды. Сабада туып-үскән кызны Түбән Ушма авылы егете Фәрит белән Казан педагогика институты таныштыра. Алар икесе дә – укытучы. Хәтта улы һәм кызлары да әти-әни сукмагыннан китеп, шушы мәктәптә укытырга кайтканнар. Гомумән, алар – укытучылар династиясе, эш стажлары 900 елга якын.

– Мәктәбебездә яшьләр күп. Үз укучыларыбыз читкә барып белем ала да кире кайталар. Шундый 6 белгечебез бар. Бу бит горурлык! Үз авылын, үз мәктәбен ярата торган балалар тәрбияли алганбыз, – ди Зәйтүнә Шакирова. – Укучыларыбыз бик актив. Спорт чараларында гел беренчелекне алып торалар. Алмасалар, оят булыр иде, бездә башка бер авылда да булмаган спорт комплексы бар. Аны Рифат Мотыйгуллин үз акчасына салдырды. Ул аның бар чыгымнарын да үзе күтәрә. Анда һәркем барып шөгыльләнә ала. Укудан соң балалар үз тренерлары белән шунда барып, көрәш, волейбол, футбол серләренә төшенә. Укытучыбыз Илшат Камалов физкультура дәресләрен үткәргәч, балалар белән шунда китә.

Ул спорткомплексны без дә күрдек. Илшат Камаловның укучылар белән бергә уйнаган вакытына туры килдек. Тырышлыкның юкка китмәвенә ул да сөенә.

Түбән Ушмада үз батырларын да онытмыйлар. Мәктәп директоры әйтүенчә, әле менә махсус хәрби операциядә катнашучы бер егетләре ялга кайтып киткән. Укучылар белән очрашып, андагы хәлләрне сөйләгән. Укытучылар исә, егетләргә дип, токмач кисә, балалар хатлар яза.

– Авылыбызның киләчәге бар, – ди Зәйтүнә Шакирова. – Киләсе елда 16 бала беренче сыйныфка керәчәк. Без – бик бәхетле авыл кешеләре. Авылда шәһәр тормышы белән яшибез. Елга берничә тапкыр укытучылар белән, ял итәргә дип, Казанга, Мәскәүгә, Санкт-Петербургка барабыз. Әмма кайда гына йөрсәк тә, Түбән Ушманы сагынып кайтабыз. Иң рәхәт, иң матур җир – монда.

...Без килгәндә, өстән яңгыр сибәләп тора иде. Ни гаҗәп, кая гына туктасак та, машинадан төшүгә, яңгыр да туктап тора. Әйтерсең, һава торышы да Түбән Ушманы кунакка кайткан кешеләргә күрсәтергә тели иде. Салават күпере, күзне иркәләде. Ә бу авылны әйләнеп чыгар өчен дә ярты көн кирәк. Милләтебезгә күп кенә зыялы кешеләрне биргән Түбән Ушмадан әле тагын бик күп шәхесләр чыгар. Ә халкы хезмәт белән данланыр. Туфрагы да уңдырышлы, суы да сихәтле, кешеләре дә тырыш Ушманың. Әлеге авылның бәхете – җитәкчеләрдән. Мөхәммәтҗан Шакиров, Рафаэль Мөхәммәтшин, Рифат Мотыйгуллин... Кем генә эшләмәсен, барысы да, авыл яшәсен, аннан кеше китмәсен, дип тырышкан. Ә халкы булганның кадерен белә, саклап тота. Адым саен рәхәт тормышлары өчен авылдашларына рәхмәт укыйлар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

«Тизләнеш» һәм «көчәнеш»...

Үзем яшәгән шәһәр урамнарында, кибетләрдә, ишегалларында мин татар сөйләмен ишетмим диярлек. Туган авылыма соңгы кайтуымда татар теле укытучысы әти-әниләренә «папа», «мама» дип дәшүче татар балалары, шуңа разый-бәхил ата-аналар барлыгы хакында ачынып сөйләде. Берничә ел элек шунда – туган авылымда мәктәптән русча сөйләшеп кайтып баручы балалар төркеменә юлыгуым хакында язган идем инде. Менә шуның ишеләрне күргәч-ишеткәч, Айдар Хәлимнең: «Сез беләмсез кая барганны?» – дип язганы кабат искә төшә, хәлне, вазгыятьне аз-маз анализлагач, татарның якасына ябышасы, аны гафләт йокысыннан яңаклап уятасы килә башлый.

Татар мохите тарая килә. Акрынлап та түгел, билгеле, бер ашкынлык белән, тизләнеш белән. «Тизләнеш» дигәннән, кечкенә чигенеш. Ул сүз бит – «көчәнеш» кебек үк, физика термины да әле. Физикада әле тагын «алмаш ток», «берәмлек», «матдә», күпсанлы башка татарча термин-төшенчәләр дә бар. Татар баласының абсолют күпчелеге ул сүзләрне бүген «ускорение», «напряжение», «переменный ток», «единица», «вещество» дип өйрәнә һәм белә. Гүя андый сүзләр татарча бөтенләй юк һәм булмаган да. Ә бит алар бар. Без аларны белдек, кулландык. Аңа карап надан калмадык. Вузга кергәч, төшенчәләрнең русчаларын да өйрәндек. Офыклар тагын да киңәйде. Бүген сорап кара син татар баласыннан: «Электр тогы көчәнеше нәрсә ул?» – дип. Күзләрен шакмакландырып, озаклап сиңа карап торачак һәм бер җавап та бирмәячәк.

Ничә гасырлар буе телне, миллилекне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклап килгән галиҗәнап татар авылы бүген татар инкубаторы булудан туктау алдында. Ул хәл килеп чыкмасын дигәндә, авыл мәктәпләренең һәммәсендә дә белем фәкать туган телдә генә бирелергә тиеш түгелме икән? Тиеш! Үсеп килүче буында татар җанлылык тәрбияләүнең, авылда татар мохитен саклап калуның, инкыйразга каршы торуның башка нәтиҗәле юлын мин күрмим. Совет чорында укыту татарча иде, нинди зыяны булды? Ә бүгенге кыланмышларның зыяны әйтеп бетергесез: телсезлек, аңсызлык, манкортлык – ахыр килеп, меңьеллык тарихны, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне тарих чүплегенә илтеп салу.

Ә юкка чыгу алгоритмы бик гади. Менә ул. Туган телдә укыту юк икән, мохит кискен тарая, тел кухня теленә әверелә, әдәби тел юкка чыга. Әдәби тел юкка чыктымы, шагыйрь-язучылар яралмый, миллилек күп дигәндә җыр-биюгә, Сабан туе үткәрүгә генә кайтып кала. Халыкның язучы-шагыйрьләре юк икән, аның мәдәнияте дә була алмый. Чөнки әдәбият – мәдәниятнең алтын баганасы. Мәдәниятсез халык – сарык көтүе. Ул башка кавемнәр мәдәниятен сеңдерә, шул кавем кешесенә әверелә. Милли телдә укытуны бетерү ул – милләтне тиз арада: ике-өч буын эчендә, хәтта тизрәк тә юкка чыгару. Тагын бер кат искәртәм: без бүген теләсә нишләргә, чәчрәп чыгарга, егылып ятарга, тик авыл мәктәпләренең барысында да бар булган фәннәрне бары татарча гына укытырга тиеш!

Туксанынчы елларда татар милли күтәрелеш, ренессанс кичерде. Без киләчәгебезгә өмет, ышаныч белән карадык. Мәгарифебез дә «барысы да ал да гөл» дип әйтерлек үк булмаса да, без теләгәнчә, дөрес юнәлештә иде. Тик аерым көчләр моны күпсенде. Барысы да белем бирү стандартларыннан милли компонентны алудан башланды кебек. Без дәшмичә генә аны йотып куйдык. Үз-үзебезне шул рәвешле тоту белем бирүдә миллилекне санга сукмаучы башка чараларга юл ачты – 2008 елның 28 ноябренә караган 362 номерлы приказ БДИны бары титул милләт телендә генә бирүне законлаштырды. Без янә килештек, атаклы милләттәшебез – академик Нигъмәтуллин киңәшен тыңламастан, ике телле БДИ өчен дә көрәшәсе итмәдек. Нәтиҗәдә бүген татар баласы үз туган телендә урта белем дә ала алмый – 10, 11 нче сыйныфларда укыту тоташтан русча. 2017 елның 29 ноябрь хәлләре исә татар теле укытуны да телим-теләмимгә калдырды.

Мохит дигәннән. Татар авылларында бүгенге чорда төрле килмешәкләр күбәйде. Урта Азия кешеләре дә бар, Каф таулары артыннан килеп чыкканнар да. Алар русча сукалый, татарча – юк. Чит монастырьга үз уставың белән килергә ярамаганны белми түгел, беләләр – татарчаны өйрәнәсебез килми, дип әйткәннәре ишетелми. Тик бу хәлдә дә татарның чиксез толерантлыгы, ярарга тырышуы тагын аның үзенә үк аю хезмәте күрсәтә башлый. Бер яисә ике бала татарча белми дип, төркемдәге, балалар бакчасындагы тәрбия тулаем русчага күчә дә куя. Ә бит ул бала татарчаны ярты ел дигәндә өйрәнә ала. Ул яшьтә алар бар нәрсәне ком суны үзенә ничек сеңдерә, шулай тиз кабул итә, үзләштерә. Юк, нәкъ менә русчага күчәргә, мохитне анда да юкка чыгарырга кирәк…

Без кайчакта үзебезне янәшәдәге башка азчылык халыклар белән чагыштырабыз да: «Менә биш гасырга якын башкалар кулында булып та без әле яшибез, без исән», – дип мактанабыз. Мактанасы түгелдер. Татар авылы узган гасырның урталарына чаклы билгеле бер изоляциядә яшәде. Әле җитмешенче елларда да без русчаны бары радиодан һәм бар кешедә дә булмаган телевизордан гына ишеттек. Бары рус теле дәресендә генә өйрәндек. Тик менә ике катлы глобальләштерү килеп, өлкән туган теле һәр үтүктән ишетелә, һәр ярыктан ургып чыга башлагач, заман бала-чага кулына смартфон тоттыргач, милли үзаңыбызның нинди югарылыкта икәне беленде. Глобальләштерү сынавын без үтә алмадык. Милли аңы күзгә кырып салырлык кына булган ата-ана газизенең русчаны яхшы белүен, шул рәвешле кеше булуын тели. «Папа», «мама» дисә дисен, русча БДИны тапшырып, вузга гына керә күрсен. Андыйларга туган тел дә бер каршылык һәм киртә генә.

Сүзне йомгаклап, безләрдәге тизләнеш һәм көчәнеш кире якка таба булмасын иде, диясе генә килә.

«КӨТӘР КЕШЕҢ БАРЫН ОНЫТМА!»

Тәтеш районы башлыгы Рәмис Сафиуллов махсус хәрби операция зонасында батырларча һәлак булган егетләрнең әти-әниләренә, өйләренә барып, даими рәвештә игътибар күрсәтергә тырыша. Шушы көннәрдә ул хәрби операция зонасына чираттагы сәфәреннән кайтты. Рәмис Сафиулловның мондый сәфәрләре 20дән артып киткән инде.

Ватан хакына

«Фронттагы тормышка ияләштек – бар да тәртип». Махсус хәрби операция зонасыннан вакытлыча ялга кайткан егетләр хәлләрен белешүчеләргә әнә шулай кыска гына җавап кайтара. Зарланмыйлар, үзләренә һәм гаиләләренә ярдәм итүләрен беләләр. Район башлыклары белән дә һәрдаим очрашып торалар.

Кайбыч

Кайбыч районы башлыгы Альберт Рәхмәтуллинның ялга кайткан хәрбиләр белән беренче генә очрашуы түгел инде. Бу юлы чара артык тантаналарсыз, ихластан сөйләшү рәвешендә узды. Егетләрне нәрсә борчый? Нәрсә җитми? Сәламәтлекләре ничек? Шундыйрак рухтагы сорауларга җавапны кыска тотты хәрбиләр. «Анда киткәнгә елдан артты. Ул арада фронттагы тормышка ияләштек – бар да тәртип», – дип чикләнделәр.

Альберт Рәхмәтуллин исә аларның үзләренә дә, гаиләләренә дә кирәкле ярдәмне оештырырга һәрвакыт әзер булуларын әйтте.

– Ничек кирәк, шулай ярдәм итәрбез. Район эшмәкәрләре, авыл җирлеге башлыклары, мобилизацияләнгән ирләрнең хатыннары инде берничә мәртәбә гуманитар ярдәм җыюны оештырды. Махсус хәрби операция зонасына 100 тонналап урман материаллары, машиналар, хәрби җиһазлар һәм башка кирәкярак җибәрелде. Киләчәктә дә мөмкинлегебез булган кадәр ярдәм җибәреп торырга ниятлибез, – диде ул. – Иң мөһиме – үзегезне саклагыз. Зарыгып көтеп торучылар барлыгын онытмагыз!

Бөгелмә

Бөгелмә мэриясендә узган «эшлекле дүшәмбе»дә «Алга» батальоны взводы командиры Артем Малючевны «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләделәр. Әлеге тантана хәрбинең ялга кайткан чагына туры килгән.

– Әлеге зур бүләк махсус хәрби операция барышында күрсәтелгән батырлык өчен бирелә. Гомумән, Бөгелмә хәрбиләре бурычларын бик яхшы үтиләр. Горурланабыз!» – диде район башлыгы Линар Закиров.

Чаллы

Автокала мэры Наил Мәһдиев ялга кайткан хәрбиләр белән чираттагы очрашуын «Шатлык» яшьләр үзәгендә уздырды.

Түбән Кама

Түбән Камадан чиратта гуманитар йөк төялгән машина юлга чыкты. Бу юлы ул Рубежное шәһәрендәге госпитальгә һәм Донецкидагы инвалидлар йортына китте. Җылы кием-салым, урын-җир, көндәлек кирәк-ярак, азык-төлек, балалар уенчыклары – район халкы җәмгысы 1,5 тонна гуманитар ярдәм җыйган. Түбән Каманың 6, 7, 8 микрорайоннарының территориаль иҗтимагый үзидарә советлары рәисе Лариса Орлова сүзләренчә, гуманитар ярдәм атна саен диярлек госпитальгә һәм махсус хәрби операция зонасына җибәрелә.

– Аны Түбән Каманың битараф булмаган кешеләре җыя. Шулай ук «Гуманитарка Татарстан. Нижнекамск» волонтерлык хәрәкәте вәкилләре дә актив катнаша. Мәгариф учреждениеләре дә, авыл җирлекләре дә бу эштән читтә калмый. Ярдәмне тиз җыябыз һәм шундук җибәрәбез, – ди ул.

Аеруча актив катнашучы гаиләләр дә бар. Әйтик, Галина Мишагина күп итеп җылы оекбашлар бәйли.

– Узган сезонда 350 пар оекбаш бәйләгән идем, быел – 210 пар. Олылар өчен дә, балалар өчен дә ярый торганнарны бәйлим, – ди ул.

– Сез шактый катлаулы хәрби бурычыгызны үтәсәгез, без, үз чиратыбызда, сезнең алда булган бурычларыбызны үтәргә тырышабыз, – дип мөрәҗәгать итте ул очрашуга килгән егетләргә.

Мәһдиев Чаллыдагы ярдәм чаралары турында да сөйләде. Шәһәр Лисичанскидан килгән балаларның лагерьлардагы ялын да, хәрбиләрнең гаиләләренә ярдәм итүне дә, күптән түгел әни булган хәрбиләрнең хатыннарына адреслы ярдәм итүне дә оештыра.

– Часть командирлары шәһәр администрациясенә өстәмә техник җиһазландыруга кагылышлы үтенечләр белән мөрәҗәгать итә. Барлык үтенечләр дә оператив рәвештә карала, – диде Мәһдиев.

Апас

Апас урта мәктәбенең 8 «Б» сыйныфы укучысы Александра Харитонова бу көнне әле озак кына хәтерендә саклар. Яз көне узган «Солдатка хат» акциясендә катнашып, махсус хәрби операция зонасына хат юллый ул. Ә күптән түгел шушы хатны алып, талисман итеп саклаган Рәмис Фәсхетдинов Александра янына кунакка килә.

– Хатта язган сүзләрең йөрәгемә тиде… Вакыт чыккан саен алып укыдым шуны. Сезнең сүзләр күңелдәге ышанычны арттыра. Без һичшиксез җиңәчәкбез! – диде хәрби.

Рәмис буш кул белән кайтмаган: хат авторына йомшак уенчык бүләк итте ул.

– Ватанны саклаучы һәр солдат якыннары янына исән-имин кайтып җитсен иде! – дип тели Александра.

Лилия ГЫЙМАЗОВА



Синеке дә, синеке дә түгел кебек

Җир мәсьәләсе

Җир участогын, гаражны рәсмиләштерү буенча проблемалар гел чыгып кына тора. Гомер буена синеке инде ул югыйсә. Документы булмагач, синеке дә түгел кебек.

Әле алай гынамы соң?! Күпләрнең әти-әни, әби-бабайлардан мирас булып күчкән мөлкәтләре белән дә шул ук хәл. Бу аңлашылмаучылыклардан күбрәк моңарчы тыныч кына яшәгән өлкән кешеләр интегә.

Шул ук вакытта Росреестр һәм Роскадастрның Татарстан буенча идарәләре бер дә борчылмаска куша.

Белгечләр әйтүенчә, әгәр гараж 2004 елның 30 декабренә кадәр, ягъни Россия Шәһәр төзелеше кодексы гамәлгә кергәнче төзелгән булса, эш бигрәк тә җиңеләя. Чөнки «гараж амнистиясе» буенча рәсмиләштерергә мөмкин. Бу очракта гаражның суд яки җирле үзидарә карары белән ирекле төзелгән объект булмавы гына мөһим. Тагын бер шарты бар: мондый җиңелләштерелгән ысул белән бары тик бер катлы гаражларны гына үзеңнеке итәргә мөмкин.

Гаражны үзеңнеке итеп раслар өчен төрле документлардан файдаланырга мөмкин. Хәтта совет чорындагы кәгазьләр дә ярый. Бәлки кайчандыр гараж төзелгән җир участогының сезгә бирелүе турында берәр документ аунап ятадыр, гараж кооперативында пай өчен түләгәнлеккә квитанцияләр җыеп куелмаганмы? Иске техник паспорт, әби-бабаларыгыз мирас итеп тапшырган яки кемнәндер сатып алу турындагы документлар да ярый. Шүрлекләрне актарып карагыз әле.

Инде эзләп-эзләп тә, бернинди кәгазь тапмасагыз, барыбер төшенкелеккә бирелмәгез. Әгәр гаражыгыз кооператив территориясендә булса, үзегезгә участок бирелүе һәм пай акчасын түләвегез турында язу барып алыгыз. Аларда гараж турында мәгълүматлар да булмый калмас. Димәк, техник план ясату буенча кадастр эшләренә чыгымнар китми дигән сүз. Әгәр дә инде бу документлар да булмаса, кадастр инженерына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ул сезгә җир участогының чикләрен билгеләргә һәм гаражның планын ясарга ярдәм итәчәк. Кыскасы, гаражга һәм җир участогына кагылышлы бер генә кәгазьне дә игътибарсыз калдырмагыз.

Хакимият документларны җитәрлек дип тапса, Росреестрның Татарстан буенча бүлегенә юллап, хокукларыгызны теркәү турындагы проблемагызны, һичшиксез, хәл итеп куяр.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЦЕНТРАЛЬНАЯ ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ КОМИССИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПОСТАНОВЛЕНИЕ

17 октября 2023 г. г. Казань № 26/174

Об утверждении результатов учета объема эфирного времени, затраченного на освещение деятельности политических партий, представленных в Государственном Совете Республики Татарстан, региональными телеканалом и радиоканалом в сентябре 2023 года

Заслушав представленную информацию и обсудив решение Рабочей группы по установлению результатов учета объема эфирного времени, затраченного в течение одного календарного месяца на освещение деятельности политических партий, представленных в Государственном Совете Республики Татарстан от 10 октября 2023 года № 117 «О результатах учета объема эфирного времени, затраченного на освещение деятельности политических партий, представленных в Государственном Совете Республики Татарстан, региональными телеканалом и радиоканалом в сентябре 2023 года», на основании статьи 5 Закона Республики Татарстан «О гарантиях равенства политических партий, представленных в Государственном Совете Республики Татарстан, при освещении их деятельности региональными телеканалом и радиоканалом» (далее – Закон Республики Татарстан), раздела VI Порядка учета объема эфирного времени, затраченного в течение одного календарного месяца на освещение деятельности каждой политической партии, представленной в Государственном Совете Республики Татарстан, региональными телеканалом и радиоканалом, утвержденного постановлением Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан от 11 ноября 2010 года № 35/392, Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан **постановляет**:

1. Утвердить результаты учета объема эфирного времени, затраченного на освещение деятельности каждой политической партии, представленной в Государственном Совете Республики Татарстан, региональными телеканалом и радиоканалом в сентябре 2023 года, содержащиеся в решении указанной Рабочей группы от 10 октября 2023 года № 117.

2. Вынести заключение о соблюдении региональным телеканалом «Телевидение «Татарстан – Новый Век» и региональным радиоканалом «Радио «Татарстан – Новый Век» – радиопрограмма «Радио Болгар (Болгар Радиосы)», учрежденными и распространяемыми АО «Телерадиокомпания «Новый Век», в сентябре 2023 года требований Закона Республики Татарстан об освещении деятельности политических партий, представленных в Государственном Совете Республики Татарстан, в равном объеме в течение одного календарного месяца.

3. Направить настоящее постановление в АО «Телерадиокомпания «Новый Век», Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ», Татарстанское региональное отделение политической партии «КОММУНИСТИЧЕСКАЯ ПАРТИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ».

4. Направить настоящее постановление для опубликования в газеты «Республика Татарстан», «Ватаным Татарстан» и разместить на сайте Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

5. Контроль за выполнением настоящего постановления возложить на заместителя Председателя Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан Нефедова А.А.

Председатель Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан А.С. Кондратьев

Исполняющий обязанности секретаря Центральной избирательной комиссии Р.Р. Валиуллова

СУКМАКЛАР ЧУАЛМАГАН

Очрашу

Район хакимияте башлыгы Альберт Хуҗинга зур рәхмәт: Рамил Муллин башлап җибәргән күркәм гадәтне дәвам иттерә – Мөслимгә язучылар салган сукмак өзелми. Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанованың бу фикерен Мөслим районында Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәренә җыелган һәр язучы куәтләде. Ә алар ике дистәдән артык иде. Ни аяныч: Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәрен үткәрү традициясе хәзер республикабызның берничә районында гына сакланып калды. Элек укучылар белән мондый кызыклы очрашулар Татарстан районнарында гына түгел, милләттәшләребез тупланып яшәгән өлкә-республикаларда да еш була иде. Әлеге сәфәр-очрашулар – беренче чиратта, әдип белән укучылар арасында кайтма бәйләнеш урнаштыру ул. Язучы сүзе халыкка барып җитәме? Халык әдиптән нәрсә көтә? Төбәкләрдә яшь алмаш булырлык каләм әһелләре шәйләнәме? Китапханәләрдә, мәктәпләрдә булган очрашуларда язучыларыбыз менә шушындый сорауларга җавап эзләде. Бу уңайдан Татарстан китап нәшрияты башлыгы урынбасары Гөлүсә Закирова Габдулла Тукай исемендәге Мөслим урта мәктәбендә оештырылган очрашудан соң: «Татмедиа» җәмгыяте, Язучылар берлеге һәм Татарстан китап нәшриятының яшь талантларны барлау, танытуны максат итеп куйган проекты уңышлы эшләп килә. Укучыларның иҗат эшләре белән танышкач, Мөслим җиренең киләчәктә дә затлы каләм әһелләре бирәчәгенә ышандым», – дип белдерде.

Автор фотосы

Рухларын яд иттек

Бу сәфәр-очрашуларның икенче бер зур мәгънәсе «Үлгәннәрнең каберен бел, исәннәрнең кадерен бел» дигән гыйбрәтле гыйбарәне тормышка ашыру булды. Иң әүвәл Бүләк авылында шагыйрь һәм мөхәррир Наис Гамбәр яшәгән йортка элмә такта куелды (йорт, ишегалды әйбәт кенә җыештырылган, төзәтелгән), каберенә чәчәкләр салынды. Шагыйрьләрне әүлияләр белән юкка гына чагыштырмыйлар. Әнә әдипнең кабер ташына мәкальдәй сүзләре уеп язылган: «Мин... туган туфрагымда, гомеремнең сыңар яфрагын да бирмәс идем көмеш-алтынга». Бүләк авылы ватаныбызга Советлар Союзы Герое Илдар Маннановны бирүе белән дә яхшы мәгълүм. Биредә каһарманны җылы итеп искә алып, бюстына баш идек, хөрмәтебезне белдердек. Түреш авылында туып-үскән шагыйрь Харрас Әюпнең каберен зиярәт кылып, анда да чәчәкләр салдык. Аның кабер ташындагы шигырь юллары безгә васыять булып яңгырый:

Дөньяларын мин дә яраттым ла,
Яраттым ла азга булса да –
Яратканнар кала... И җир йөзе!
Миннән соң да назга сусама...

Октябрь (Теләнче) авылында туып-үскән, яшәгән күренекле мәгърифәтче, фольклорчы, язучы Зариф Мөэминовның тууына – 130 ел, Мөслим авылында туган язучы-прозаик, журналист Флүс Латыйфиның тууына 80 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә әлеге күркәм көннәрнең йөзек кашы булды. Аларның каберләрен дә зиярәт кылып, гүрләре якты, рухлары шат булса иде, дип дога кылдык.

Чакмак эрмитажы

Олы Чакмак – әдәбиятыбызга Мөслимнең горурлыгы, мактанычы булган, гомере буе шушында яшәп иҗат итүче, Тукай бүләге иясе Фоат Садриевны биргән авыл. Укучылар белән очрашуга кайтканда, Олы Чакмак авыл җирлеге башлыгы Илнур Габидуллин: «Безнең карьядан шушындый атаклы кеше чыгуы гаҗәп түгел. XIX гасырда авылыбыз тирә-якның мәгърифәт үзәге булып танылa, 1830 елда ачылган мәдрәсә бик күпләргә төпле гыйлем бирә», – дип сөйләде. Авылдашларының өлкән әдипне кадерләп, зурлап торуы мәктәп бинасында ачык күренә. Анда әдипнең күркәм музее эшләп килә. «Чакмак эрмитажы» дигәннәре авылның тагын бер горурлыгы икән. Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе Факил Сафин, Чаллы сәнгать мәктәбе директоры Мадияр Хаҗиев белән киңәшләшеп, мәктәптә саклаучы чыгарылыш класс укучыларының диплом эшләреннән авыл клубында һәм мәктәптә даими эшләп торучы рәсемнәр күргәзмәсе булдырган. Бүген клуб һәм мәктәп диварында Чаллыдан кайтартылган йөздән артык рәсем эленеп тора. Олысы-кечесендә сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүче, иҗади фикер уятучы мондый күргәзмәне һәр районда, һәр мәктәптә оештырырга була лабаса. Мөслимдә моның матур үрнәге бар.

Рәшит МИНҺАҖ

Милләттәшләр

БЕЗНЕ ЙОКЫДАН УЯТТЫГЫЗ

Альберт Борһанов архивыннан

Бик күп тарихи урыннар белән танышырга туры килде.

Чит төбәкләрдә моңа кадәр эшне нидән башларга яки ничек дәвам иттерергә икән дип аптырап яткан милләттәшләребез үз юлларын тапканнар, юнәлешләрен ачыклаганнар дигән сүз инде бу. «Җаек (Урал) елгасы бассейны татарлары: тарих һәм хәзерге заман» IX Евразия фәнни-төбәк тарихын өйрәнүчеләр форумына нәтиҗә ясаганда бу фикер еш әйтелде. Мондый яктылык Бөтендөнья татар конгрессының Альберт Борһанов җитәкчелегендәге төбәкне өйрәнүчеләр оешмасыннан делегация килгәч пәйда булган.

Чаба поезд, чаба...

Бу милли хәрәкәтне поезд белән чагыштыручылар да булды. Чыннан да, ошаган икән шул. Казаннан киткән десант, төрле тукталышларда туктый-туктый, газиз җиребезне ураган да ураган. Берәүләре төшеп калган (дөнья мәшәкате дә гел чабудан тартып тора бит), икенчеләре, киресенчә, менеп утырып, олы юлын берәр шәһәрдән башлаган. Шулай итеп, делегация составы да гел алышынып торган. Татарстаннан тыш, Россиянең Башкортстан, Мари Эл, Удмуртия республикаларыннан, бик күп шәһәрләреннән, Казахстаннан төрле белгечләр катнашкан. Нәтиҗә ясарга килгән кунакларның да, онлайн катнашучыларның да (алар 40тан артык кеше иде) авызында бер сүз: без әле һаман шул хисләр белән яшибез. Арада нинди генә һөнәр ияләре юк: галимнәр, эшмәкәрләр, сәнгать әһелләре, язучылар, журналистлар, татар оешмалары вәкилләре... Барысының да – үз эше. Берәүләр тарих эзләренә басарга тырыша, икенчеләре татар әдәбияты һәм сәнгатен терелтә, өченчеләре бар булганны халыкка җиткерә, тәҗрибә уртаклаша. Альберт Әхмәтҗанович әйтүенчә, болар барысы да һәм берьюлы кирәк.

– Галимнәр генә булса, алар фәнни эшләрне генә күздә тотар иде. Гади халык бу хакта белми дә калырга мөмкин. Чит төбәкләрдә яшәгән милләттәшебез татар моңын, шагыйрь сүзләрен ишетеп, тарихны да белеп торса, без үткәргән чаралар күпкә үтемлерәк була. Ә журналистларның исә үзләренә аерым миссиясе: алар татар дөньясындагы бу яңалыкларны бар җиһанга җиткерә. Кыскасы, юнәлешләр бик төрле. Без инде 2015 елдан бирле эшләп киләбез. Соңгы биш елда гына да 208 конференция, 9 форум үткәрдек. Баштарак беренче чиратта татар тарихына игътибар итә идек. Хәзер табигать байлыклары, архитектура объектлары, кабер ташлары, хәтта борынгы чишмәләргә кадәр күз уңында тотабыз. Шул ук вакытта юкка чыккан авылларны да барлыйбыз. Монысы башка мондый хәл килеп чыкмасын өчен кирәк, – диде ул.

Нәтиҗә ясар чак

Аңлашыла ки, мондый сөйләшүнең үзәгендә – татар язмышы. Бәхәсләргә дә урын табыла.

– Милли хәрәкәтнең бигрәк тә чит өлкәләрдәге татар авыллары буйлап йөрүе – бик күркәм күренеш, – дип башлады сүзен Бөтендөнья татар конгрессының беренче рәисе Индус Таһиров. – Чөнки авыл татарны саклап калачак.

Профессор Хатыйп Миңнегулов исә бу сүзләргә азрак өстәмә кертте:

– Авыл, чыннан да, татарлыкны саклый. Әмма хәзер милләттәшләребезнең төп өлеше шәһәрләрдә яши. Алар белән дә эшләргә кирәк. Ә менә ничек эшләргә? Монысы – икенче мәсьәлә. Үзебезне кайгыртмасак, безне беркем дә кайгыртмас. Күпме үзгәрешләр кичердек бит. Элек, хәтерлисездер, Чиләбе өлкәсендәге авылларда татар мәктәпләре гөрләп тора иде. Хәзер ул якларга барсаң, авыр сулап куярга гына туры килә. Хәер, ерак барасы түгел. Татарстан шәһәрләрендә әле күптән түгел генә татар-төрек лицейлары эшләде. Барысы да юкка чыкты. Бу мәсьәләне кузгатуым юкка түгел: беренче чиратта милли мәгариф турында уйларга кирәк. Мәктәпләребезне торгыза алсак, киләчәгебез өметле булыр иде.

«Мәдәни җомга» газетасы мөхәррире Вахит Имамов форум кысасында татар җирләрен үз күзләре белән күреп барлап кайткан.

– Татарларның бөтен Россия буйлап йөри алулары – үзе бер гаҗәеп күренеш, – дип фикерләрен җиткерде ул. – Әйтегез әле, кайсы милләт бөтен ил буйлап шулай үзен хуҗа итеп сизеп йөри ала? Бары тик татарлар гына. Чөнки без йөргән төбәкләрнең барысында да бабаларыбыз яшәгән.

Татарстаннан бер төркем язучы турыдан-туры Муса Җәлилнең туган авылы – Оренбург өлкәсендәге Мостафа авылы тукталышына юл тоткан. Сере дә бар. Алар герой-шагыйрьнең кызы, Санкт-Петербургта яшәүче Люция апаны беренче тапкыр әтисенең туган җиренә алып кайтканнар.

– Оренбург, ниһаять, Җәлилнең кызын күрде. Без моны эшләргә тиеш идек. Битарафлыгыбыз аркасында, Мусаның бер мәхәббәт җимешен – Альберт абыйны эзсез югалттык. Бу – татарның тирән бер ярасы, – дип дәвам итте Вахит Имамов бу җәһәттән. Аңа «Мирас» журналы мөхәррире Ләбиб Лерон кушылды.

– Шунысы күңелне сөендерә: безнең татарга ни сорасалар, шуны бирәләр. Әмма көендергән ягы да бар: шул биргәнне кулыбызда тота алмыйбыз. Мәсәлән, мәчетләр белән шундый хәл. Татарларга атап төзиләр, ә анда бөтенләй башка халыклар йөри башлый. Кыскасы, бердәмлек җитеп бетми бездә. Дөрес әйтәсез, күбрәк йөрергә кирәк. Чит җирләр түгел бит, кайчандыр татар байлары гөрләтеп яшәгән төбәкләр. Люция апаны Санкт-Петербургта күреп кайткан идек. Әтисенең туган җирендә без аны бөтенләй яңа яктан ачтык. Бар кешене сокландырып та, гаҗәпләндереп тә, зиратка барып, әби-бабаларына дога укыды. Әтисенең рухы алдында баш иеп кайтты ул. Үзе дә бик канәгать калгандыр дип уйлыйм. Люция апа гел татарча гына сөйләшкәч, Оренбургта яшәүче милләттәшләребез арасында, безгә дә өйрәнергә кирәк, оят бит, дип әйтүчеләр дә булды.

Әлбәттә инде, киләсе елга планнар турында да сөйләштеләр «түгәрәк өстәл» янында:

– Ни кызганыч, татар тарихы ярылып ята торган җирләрдә институтлар юк. Төбәкчеләр бу җәһәттән нык ярдәм итә. Әйтергә кирәк, безнең бу милли хәрәкәтебез институт дәрәҗәсенә күтәрелде. Хәзер инде 2030 елда булачак халык саны алу кампаниясенә әзерләнәбез. Төбәкләрдә мондый чаралар үткәрү җиңел генә бирелми. Башта губернаторның ризалыгын алырга кирәк. Аннан татар оешмалары белән элемтәгә чыгып, планнар төзергә. Киләсе елда Сарытау, Волгоград якларындагы милләттәшләрне барларга исәп. Шунысы куанычлы: кая гына барсак та, без ялгыз түгел, татарның үз сүзен әйтерлек шәхесләре, ярдәм кулы сузарлык эшмәкәрләре бар, – диде Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчесе Данис Шакиров бу җәһәттән.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Авыл рухы

Үз җирем

Үз авылым дип, булсын дип тырышып йөрүче кеше генә нәтиҗә өчен эшли. Килмешәктә башка холык, башка уйлар... Аллага шөкер, безнең авылда да «үзебезнеке» дип горурланырлык кешеләр бар. Кырык ике ел, армый-талмый, авылның мәдәни учагын сүндермичә, алай гына да түгел, елдан-ел яктырак яндыра алучы «завклуб»ыбыз Илсөяр Дәүләтшина турында бүгенге язмам. Чаллы Башы мәдәният йорты мөдире, районның «Ак калфак» хатын-кызлар берләшмәсе җитәкчесе ул.

Кеп-кечкенә, якынча биш йөз кешелек авылда мәдәният йорты каршында тугыз коллектив эшләп килә. Яңа Чишмә районындагы бердәнбер халык театры да – безнең Чаллы Башы авылында! Уналты кешене берләштергән әлеге «Заман» театры белән кайларда гына булмаган инде алар. Ел саен «Идел-йорт» театр фестивалендә катнашалар, еш кына Казанга кадәр барып җитәләр. Шәһәр театрлары белән көндәшлек, әлбәттә, бераз ризасызлык тудырса да, уңышлар да шактый: күп дипломнар, рәхмәт хатлары... «Тамашачы күңелен яулаган» Илсур Гатауллин, «Икенче пландагы иң шәп хатын-кыз роле»н башкарган Гөлнара Сәлахова да үзебезнеке. Гөлнара ханым – театрның режиссеры да әле; кызы Алсу Сәлахова да шигърият дөньясында үзенчәлекле яшь шагыйрә буларак күренә башлады. Быел Рәзинә Сәетгәрәеваның «Тәүбә йорты» спектакле белән Яңа Чишмә районы авылларында гына түгел, Чистай, Аксубай якларында да, авторның туган авылы Бикләндә (Тукай районы) дә зур уңыш белән чыгыш ясадылар. 2022 ел азагында гына «Талир тәңкә» ансамбленә дә «Халык ансамбле» исеме бирелде!

Мәктәп балаларын «Өмет» балалар театрына җәлеп иткәннәр. Энемнең кызы «Такмаза» төркеменә йөри. Анда халык йола-уеннарын өйрәнәләр.

Авылга бәйрәм тирәләрендә кайтырга туры килсә, сәхнәдә биючеләрнең күплегенә һәм осталыгына шаккатасың. Без дә үскәндә биеп йөргән идек үзе, тик безнең биюләребез бер-берсенә игезәктәй охшаш дүртбиш хәрәкәттән торса, хәзергеләр сәхнәдә ут уйната!

– Хәзер, бердән, һәр биюнең костюмы бар, икенчедән, алар – чынлап та, ансамбль. Яшүсмерләр – «Ритм» бию түгәрәгенә, кечерәкләр «Тамчы» бию түгәрәгенә йөри. Әле кайчан гына «Тамчы» ансамбле биючесе булган Минабетдинова Динәнең дистәгә якын алтын медале, әллә ничә дистә кубогы бар инде. Бәйгеләрдә җиңеп, Санкт-Петербургка, Кырымга барды, – ди Илсөяр апа, горурланып.

«Тел Киевка җиткерер» дигән мәгълүм гыйбарәне үзгәртеп, сәләт дөнья гиздерер, диясе килә. Шул сәләтле балаларны күреп алып, үстерү өчен шартлар булдырырга гына кирәк шул. Хәзер инде Динә киңрәк мәйданга чыккан – Яңа Чишмә сәнгать мәктәбендә «Шешминка» төркемендә бии, киләчәген дә биюче буларак күзаллый... Күршебез Гөлүсә Әдһәмова да, берара профессиональ биюче булып, Гүзәл Уразова төркемендә йөрде.

Глобальләшү, интернет безнең авылны гына читләп үтмәгән – буш вакытны телефон-смартфоннар урларга гына тора. Киләчәк буынны тамырсыз космополитлар итмәүнең иң нәтиҗәле ысулларының берсе – аларны үз милли үрнәгеңдә тәрбияләү. Шунлыктан нинди генә чара узса да, балаларны катнаштыру ягын карыйлар биредә.

Бу урында «Талир тәңкә» ветераннар ансамбленең ни дәрәҗәдә зур эш башкаруын әйтми булмый. Авылның элеккедән килгән йолаларын, гореф-гадәтләрен өлкән яшьтәге абый-апалардан да яхшырак кем белсен инде!

Кычыткан бәйрәме, Алма бәйрәме, Бәрәңге бәйрәме... Бүгенге авылга бу төр бәйрәмнәр дә кирәк икән бит. Бердән, авылдашларны берләштерә ул, икенчедән, онытыла башлаган ризык-тәгамнәребезне искә төшертә.

Илсөяр апа белән уңышлары-сөенечләре турында озак сөйләшеп булыр иде. Оптимист ул! Эшли алганда, эшләргә һәм булдыра алганча яхшырак эшләргә кирәк, дип саный ул. Девизы – «Минем белән дөнья яхшырак, матуррак, кызыграк булсын!» (Монысын үзем уйлап чыгардым, миңа шулай тоела.)

Борчуларга килгәндә... Илсөяр апаның менә нәрсәләргә йөрәге әрни: «Авыллар «картая» хәзер. Балалар азая, укытучыларга гына түгел, безгә дә эшләү авырая бара. Бик күп түгәрәкләр, бәйрәм-чаралар мәктәп укучылары белән оештырыла бит. Җырчылар да алар, биючеләр дә, театрда да уйныйлар. Һаман шул ук балалар. Әлегә алар барлыгы егермеләп иде. Мәктәп, быелдан башлангычка калып, балалар бакчасы бинасына күчерелде... Шахмай, Яңа Чишмә мәктәпләрендә укыйлар балалар, аларны укудан соң, юлдан соң мәдәни чараларга тартуны уйларга кирәк.

Авылда эш булмагач, яшьләр китә, шунысы аяныч. Ә бит авылга кайтып төпләнерлек яшьләр бар. Авылда булмаса, район үзәгендә булса да күбрәк эш урыннары ачсалар, кайтырлар иде әле. Быелдан бушап калган мәктәп бинасында да берәр һөнәрчелек үзәгеме, җитештерү цехымы ачып булыр иде... Әгәр якын елларда үзгәрешләр булмаса, бездә дә «Талир тәңкә» кебек олылар төркемнәре генә калачак, дип борчылам...

Элек һәр чарага ныклап әзерләнеп, яратып, рәхәтләнеп эшли идек, хәзер бөтен эшләр юл уңае эшләнә кебек, тәмен-ямен табып эшләргә вакыт юк. Элеккеге яшьләр матур итеп уеннар уйный белә иде, хәзергеләр телефоннан аерыла алмый, виртуаль дөнья чын дөньяның мизгелләрен урлый; тормышның шул моментында яшәргә комачаулый. Бу бигрәк тә шәһәрдән кайтканнарның күпчелегенә карый. Аларда олыларга хөрмәт, дистанция саклау кебек сыйфатлар югала бара, шунысы да борчый...»

Иманым камил, авылның бүгенгесе өчен шул рәвешле янып-көеп яшәүчеләр булганда, аның киләчәге әле өметсез түгел. Телебез, гореф-гадәтләребезне саклап, баетып торучы иң куәтле фактор бит ул авыл. Татарның элитар, зәвыклы мәдәниятен булдыру, үстерү вазыйфасы шәһәрдә булса, аның халыкчан тирәнлеген, аһәңлелеген, җорлыгын, моңын авыл саклый. Гади генә Чаллы Башы («Чишмә башы») авылы да шул татар рухын саклауга үзеннән матур өлеш кертә. Киләчәктә дә гөрләп яшәсен өчен, авылның бары икенче канатын гына ныгытасы бар. Беренчедән, халыкны эшле итәсе. Ә аның мәдәни ягын оештыруның осталары бар биредә, анысында шик юк.

Лилия ФӘТТАХОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ВӘЛИЕВ РАЗИЛ ИСМӘГЫЙЛЬ УЛЫ
(04.01.1947 – 20.10.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Язучы, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Вәлиев Разил Исмәгыйль улы 20 октябрьдә 77 нче яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Разил Вәлиев 1947 елның 4 гыйнварында ТАССР-ның Түбән Кама районы Ташлык авылында туа. Башлангыч сыйныфларда укыганда ук матур әдәбият белән кызыксына башлый. Шул чагында беренче шигырьләре һәм хикәяләре дөнья күрә.

СССР Язучылар берлегенең Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлаганнан соң «Ялкын» журналы редакциясендә эшли башлый. Әдәби иҗаты белән җәмәгать эше белән бергә алып бара. 1984 елда ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары итеп сайлана. 1986 елда Ленин исемендәге Республика фәнни китапханәсенә җитәкче итеп билгеләнә.

Разил Исмәгыйль улы 1960 нчы еллардан соң әдәбиятка килеп керүгә үк нәфис лиризмы, тирән фәлсәфәсе, теленең метафоралары бик бай булуы белән игътибарны җәлеп итте. «Яшен тамыры» (1977 ел), «Ядкарь» (1987 ел) җыентыклары басылып чыккач, тәнкыйтьчеләр аны «дәртле фикерле шагыйрь» дип бәяләде. Аның шигърияте, прозасы һәм драматургиясе югары дәрәҗәдә гражданлык хисе һәм әхлаклылыгы кешене һәм туган җир язмышын кайгырту белән сугарылган.

1990 елда Разил Вәлиев XII чакырылыш Татарстан Республикасы Югары Советы халык депутаты итеп сайланды. 1992–1995 елларда Татарстан Республикасы Югары Советының Милли мәсьәләләр һәм мәдәният комитеты буенча даими комиссиясе рәисе булды. 1995 елдан – I–V чакырылышларда даими нигездә эшләүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты. 2000–2019 елларда республика парламентының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты һәм комиссияләренә җитәкчелек итте.

Разил Исмәгыйль улы Татарстан Республикасының бүгенге дәүләтчелеген торгызуга, аның мәдәни күптөрлелеген саклау һәм милләтара татулыкны ныгытуга үзеннән зур өлеш кертте. Аның катнашында «Татарстан Республикасында дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында», «Татар телен Татарстан Республикасында дәүләт теле буларак куллану турында», «Мәгариф турында», «Мәдәният турында», «Фән һәм фәнни эшчәнлек турында» һәм башка шундый республика законнары эшләнеп кабул ителде. Ул туган телне, татар халкының мәдәниятен һәм традицияләрен саклау, үстерү буенча күпкырлы эшчәнлек алып барды. «Татар ПЕН-үзәге» язучылар төбәк иҗтимагый оешмасын җитәкләде. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе әгъзасы, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы әгъзасы булды.

Разил Вәлиев – бик күп популяр җыр сүзләре авторы. Аның «Ватаным», «Татарстан», «Сагынам», «Иң якты йолдыз», «Зиннар өчен, кермә төшләремә», «Бер алманы бишкә бүләек» кебек үлемсез әсәрләре татар мәдәниятенең алтын фондына керде.

Разил Исмәгыйль улының күпьеллык әдәби һәм иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге зур бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – «Дуслык» ордены, «Фидакарь хезмәт өчен», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медальләре, «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре», «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре», «Татарстан Республикасының халык шагыйре», Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе, «Парламентчылыкны үстерүгә өлеш керткән өчен» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мактау билгесе, Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәте һәм башка бүләкләр.

Разил Вәлиев максатка омтылышлы, талантлы шәхес, игътибарлы һәм игагатьле остаз иде. Ул һәрвакыт тормышта актив позициясе, ватанпәрвәрлеге, иҗтимагый бурычка һәм үз эшенә тугрылыгы белән аерылып торды.

Разил Исмәгыйль улы Вәлиевнең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә саклаunion.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ,
Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН,
Ә.Ә. САФАРОВ, М.Г. ӘХМӘТОВ,
В.Г. ШӘЙХРАЗЫЕВ, И.Х. ЮПОВА,
А.С. СӘЛИМГӘРӘЕВ, Р.Р. ЗӘЙДУЛЛИН,
Р.Х. МУЛЛИН, И.Ю. ӘМИНОВ

АТЫЛГАН ЙОЛДЫЗ

ТАТАР ҖӘМГАТЬЧЕЛЕГЕ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ РАЗИЛ ВӘЛИЕВ БЕЛӘН ХУШЛАШТЫ

«Минем инде бөтен нәрсәм дә бар. Миңа сәламәтлек теләгез», – дигән иде ул әле узган ел гына, үзенең юбилей кичәсендә. Ни кызганыч, якыннары, дуслары, иҗатташлары, укучылары никадәр генә теләсә дә, яман авыру көчлерәк булып чыкты. Инде бик моңсу хәбәр алдык. Күрәчәге рухлы шагыйрь Разил абый Вәлиев якты дөнья белән исәп-хисапны өзгән икән.

Могиканнар китә, җаннары тыныч булсын.

Шагыйрьне Камал театрыннан озаттылар. Халык хушлашу мәрасименә ташкын булып агылды, күпләр күз яшьләрен тыя алмадылар. Әлбәттә, һәр кеше күңеленә шәҗәрәсен йөртеп калырга ашыкты. Кайгы уртаклашу, фикер алышулар хушлашканнан соң да дәвам итте. Без аларның кайберләрен газета укучыларга тәкъдим итәбез.

Кеше китә – эше кала. Разил абыйның эше, шөкер, бернichә кеше гомеренә җитәрлек. Бу хакта Татарстан Дәүләт Советы Рәисе **Фәрит Мөхәммәтшин** менә ниләр сөйләде:

– Республика җәмәгатьчелеге авыр кайгы кичерә. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев, татар җәмәгатьчелеге исеменнән аның гаиләсенең, хезмәттәшләренең, дусларының кайгысын уртаклашам. Разил Вәлиев кечкенәдән әдәбият белән мавыга. 1986 елдан 14 ел буе Милли китапханәне җитәкли, аның язмышы өчен чын йөрәктән кайгыра. Разил Вәлиев тырышлыгы бәрабәренә китапханәгә милли статус бирелә, сирәк китаплар һәм кульязмалар булеге оеша. Парламентта озак еллар бергә эшләдек. Ул кешеләргә хезмәт итүне үзенең төп бурычы дип санады. Тормыш һәм хезмәт юлында милли мәдәни мирасны саклауга барлык көчен куйды. Шушы күркәм эшләре белән киң җәмәгатьчелекнең мәхәббәтен яулады. Аның иҗаты – Татарстанның горурлыгы һәм байлыгы. Дүрт чакырылышта депутат булып эшләү дәверендә халык ышанычын казанды. Озак еллар Дәүләт Советының Мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитетын җитәкләде. «Татарстан Республикасында дәүләт законнары турында», «Татарстан Республикасында татар телен дәүләт теле буларак куллану турында»гы кебек мөһим законнарны әзерләүдә катнашты. Габиятә аңа күпьяклы талант биргән. Нинди генә эшкә алынса да, җиренә җиткереп эшли иде. Ул безнең йөрәкләрдә мәңге саклаnыр.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил ЗӘЙДУЛЛА мәрхүмне әдәбиятта ат уйнаткан кеше дип искә алды:

– Разил абыйның авыруын белә идек инде. Атна-ун көн элек хәлен белергә дә бардым, хәле авыр иде. Кәтелгән дә үлем кебек иде, әмма бу хәбәрне ишеткәч, башка суккан кебек булды. Без бит аның белән ярты гасырдан артык аралаштык. Мәктәптә укыган вакытта Казанга килгәч, ял көне булган икән ул, нәширияткә кергән идем. Бина буп-буш, бер кеше юк. «Ялкын» журналы ишеге генә ачык. Бүлмәдә бер мыеклы егет утыра. Соңыннан, шаяртып: «Синнән, каян белдең ял көне минем монда килеп эшләгәнне, дип сорадым. Син, шагыйрьләрнең ял көне юктыр дип уйладым, дип җавап бирдең», – дип сөйләгән иде. Шуннан бирле без аралаштык, иҗатташ та, якын дуслар да булдык. Ул – мәйдан тоткан шагыйрь, прозаик, драматург, публицист – татар әдәбиятында ат уйнаткан кеше. Аннары җәмәгать эшлеклесе, дәүләт эшлеклесе. Аның сүзе һәрвакыт төпле, үтемле булды. Шуңа республикабыз, татар халкы бик зур югалту кичерә. Бик зур кайгыда барыбыз да.

Туган җирендә зурланган кеше – иң бәхетле кеше. Разил абый әнә шулай диярgә ярата иде. Ул бәхетле, түбәнкамалылар аны үз йолдызы дип йөртә. Түбән Кама районы башлыгы Рамил МУЛЛИН әнә шулай ди:

– Һәрбер җирлекнең үз йолдызы бар. Разил абый Түбән Каманың иң зур йолдызларының берсе иде. Аның нуры Түбән Камада гына түгел, Татарстан күгендә, Рәсәй күгендә балкып торды. Мин киләчәктә дә шулай булыр дип өметләнәм. Чөнки адәм баласы дөньяга килә дә китә. Аның эшләре кала. Аның турында сүз кала. Гамәлләре аркылы аңа бәя бирелә. Аллаһы Тәгалә биргән 76 елда, әлбәттә, төрле чак булгандыр. Без бүген яхшысын гына искә алабыз, чөнки ул яхшылыклар бик күп иде. Ул ватанпәрвәр, батыр булды, милләт өчен хезмәт итте. Разил Вәлиев безнең өчен укытучы булды. Безнең җирлек өчен күп хезмәт кылган, туган ягы өчен янып торган кеше иде. Хәзер инде безнең вазыйфа – аның мирасын саклау – ватаныбыз өчен, милләт өчен, телебез өчен хезмәт итү. Әгәр дә шул булса, аның хезмәте дәвамлы булыр.

«Ул минем иҗатташ дустым гына түгел, ир-егетләр арасында якын дустым иде». Татарстанның халык язучысы Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА әнә шулай диде:

– Разил Вәлиев минем өчен иң якын кешеләрнең берсе иде. Иҗатымда да, шәхси тормышымда да бик зур роль уйнады. Тукай премиясен алгач, миңа иң беренче котлап шалтыраткан кеше дә Разил абый булды. «Беләсеңме, Нәбирәҗан, – диде (миңа ул, яратып, гел шулай дәшә иде), – синең өчен иң сөенгән кеше – мин ул». Бу бит инде – бик зур сүз. «Идел» журналында баш мөхәррир булып эшләгәндә дә Разил абый янына Дәүләт Советына барып йөрдем. Аның бер генә тапкыр да, вакытым юк, эш сәгатем тәмам, дип әйткәне булмады. Утыртып, рәхәтләнеп бөтен моң-зарыңны тыңлап, киңәшләрен биреп озата иде. Шундый кешеләрнең берсе Туфан абый булса, икенчесе Разил абый булды. Аларның ишекләре беркайчан да ябылмады. Татар өчен, милләтем, дия-дия, йөрәген яндырды ул. Аның кебек йөрәккә бөтен нәрсәне якын кабул итеп, җаны аша уздырган милләт кешеләребез бик аз.

Шагыйрә Гөлүсә БАТТАЛОВА исә, һәр кешене якын итте, дип искә алды:

– Мин әдәбият мәйданына килеп кергәндә, ул инде бик зур шагыйрь, олпат шәхес һәм депутат иде. Шуңа да карамастан, кешене якын, үз итә белә иде. «Син яшь әле», – дип, кешене аермады, һәрвакыт тиң итеп сөйләшә, үсендереп торды. Яшь иҗатчылар арасында аерым дәрәҗәсе бар иде аның. Шәхсән минем өчен дә, яшь иҗатчылар, җырчылар, композиторлар, шагыйрьләр – бөтенебез өчен шундый зур, бик авыр югалту бу. Иң олпат шәхесләребезнең берсе китте. Зинһар, рәнҗеп китә күрмәсен. Чөнки депутат булган соңгы елларында татар теле мәсьәләсендә аңа шактый гына авыр сүзләр дә әйтелде. Ул аларны дәшми генә йота белде. Бәлки шул да аның тиз китүенә сәбәпче булгандыр, дип уйлыйм. Иҗаты яшәсә, шәхес үлми, диләр. Разил абыйның иҗаты бик саллы. Менә шул иҗатның яшәвен теләр идем мин. Киләчәк буыннарга да Разил абый яктылыгында хезмәт итүне теләр идем.

Тәрҗемәче, язучы Фатих КУТЛУ Разил Вәлиев янында соңгы мизгеленәчә булган. Ул да аны, икенче әти кебек якын иде, дип искә алды:

– Разил Вәлиевнең 2007 елда төрек телендә «Зәңгәр сагыш» дигән китабы чыкты. Менә шул китапны әзерләгәндә, шигырьләрен тәрҗемә иткәндә без якыннан танышып, дуслашып калдык. Мине Татарстан Язучылар берлегенә дә Разил абый тәкъдим итте. Разил абый бик инсафлы, һәр кешегә ярдәм итәргә әзер, беркемне дә кире какмаган, һәрвакыт мөлаем, шәфкатьле, мәрхәмәтле кеше иде. Разил абый әти кебек кеше булды. Соңгы көннәрендә мин аңа үзем яздым. Хәбәр алмагач, Язучылар берлеге Рәисе Ркаил абый Зәйдуллага шалтыраттым. Аның янына барасым, Корьән укыйсым килә, тынычланыр иде, дип, гозеремне җиткердем. Ркаил абый, гаиләсенә шалтыратып, очрашуны оештырды. Шуннан янына барып йөри башладым. Хәленә карап, көн дә килергә тырыша идем. Азан әйтеп, Корьән укыдым, сөйләшергә тырыштым. Разил абый аңында булды, кешеләрне таный, әз-мәз сөйләшә иде. Бер көн алдан, 19ы көнне дә шалтыраттым, Алия апа: «Бик арыды, бүген килмәсәгез дә була», – дип әйтте. Иртә белән, әтинең хәле авыр, килә алмассызмы икән дип, кызы шалтыратты. Шуннан мин аларга йөгердем. Сигезләрдә ясин укый башладым. Өченчесен укып чыкканчы китеп барды… Разил абыйны тыныч кына җан бирде дип уйлыйм. Без аны сизмәдек тә, ул бары тынып калды. Соңгы минутларда янәшәсендә булырга Ходай насыйп итте, аның рәхмәте булды дип уйлыйм. Разил абыебызның урыны оҗмахта булсын.

Разил Исмәгыйль улы Вәлиевне Курган зиратында җирләделәр. Янәшәсендә генә галим Фәндәс ага Сафиуллинның мәңгелек йорты. Могиканнар китә, җаннары тыныч булсын.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА, Ләйсән САФИНА

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, XII чакырылыш (1990–1995) ТАССР Югары Советы депутаты, I–V чакырылыш (1999–2019) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, II–V чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты һәм даими комиссиясе рәисе, IV һәм V чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы, танылган язучы, публицист, Татарстан Республикасы халык шагыйре
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйль улының
гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Разил Исмәгыйль улы, Татарстанның сәяси үсешенә, мәдәнияты һәм сәнгатьне үстерүгә лаеклы өлеш кертеп, республикада парламентчылыкны үстерүнең чишмә башында торды. Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен яклау, Россияда федерализмны үстерү буенча нык фикердә торуы, республиканың дәүләт телләрен, Татарстанның тел һәм мәдәни күптөрлелеген саклау һәм үстерү, милләтләр, диннәр арасындагы тынычлык-татулыкны ныгыту буенча күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге, күпкырлы әдәби иҗаты аңа зур абруй-хөрмәт китерде.
Разил Вәлиевнең – танылган шагыйрь, прозаик, драматург, публицист, тәрҗемәче һәм 200дән артыграк популяр җыр сүзләре авторының иҗаты инде күптән республикада танылу гына түгел, бәлки Россия күпмилләтле мәдәниятенең аерылгысыз өлешенә дә әйләнде. Разил Вәлиевнең шигырьләре татар халкының күңелендәгесен ачып сала, Ватаныбызны, мәдәниятне, халыкның гореф-гадәтләрен, әхлагын чагылдыра. Бу шигырьләр, шагыйрь үзе кебек үк халык күңеленең чын мәгънәсендә бер кисәкчегенә әйләнде, дип әйтү мөмкинлеге бирә.
Разил Исмәгыйль улы Вәлиевнең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә саклаnыр.

Танылган җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, күренекле язучы, шагыйрь һәм Татарстан Дәүләт Советының элеккеге депутаты
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйль улының
вакытсыз арабыздан китүенә бәйле рәвештә, аның туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклашам.
Нинди генә югары урыннарда хезмәт куйса да, Разил Исмәгыйль улы Түбән Кама халкын күз уңында тотып, шатлыкларын уртаклашып, кайгыларын бүлешеп яшәде. Күп еллар Татарстанга, аның халкына намус һәм дәрәҗә белән хезмәт итте, бу игелекле эшкә бөтен көчен, талантын, максатчанлыгын, тәҗрибәсен һәм энергиясен бирде.
Разил Исмәгыйль улы зур җаваплылык, хезмәт сөючәнлек, кешеләргә ихлас мөнәсәбәт, үз эшенә чиксез бирелгәнлеге белән аерылып торды. Аның күпкырлы иҗаты гомуммилли мираска әверелде, укучылар күңеленә юл тапты.
Яраткан язучы, талантлы кеше турындагы якты истәлек безнең йөрәкләрдә мәңге саклаnыр.
Разил Исмәгыйль улы Вәлиевнең гаиләсенә, туганнарына сабырлык, сәламәтлек телим.
Айдар МЕТШИН, РФ Дәүләт Думасы депутаты

Татарстан Хисап палатасы коллективы һәм палата Рәисе Алексей Демидов, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасы халык шагыйре, бернichә чакырылыш Татарстан Дәүләт Советы депутаты, танылган дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйль улының
кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Республика авыр югалтуга дучар булды. Татарстан мәдәниятен үстерүгә һәм татар телен саклауга үзеннән саллы өлеш керткән олы йөрәкле, якты күңелле кеше арабыздан мәңгегә китте. Мәрхүмнең урыны җәннәттә булсын. Якыннарына түземлек һәм ныклык бирсен.

ТАИФ төркеме коллективы, күренекле язучы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының элекке депутаты
ВӘЛИЕВ
Разил Исмәгыйль улының
77 нче яшендә гомере вакытсыз өзелү сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Разил Исмәгыйль улы татар телен саклауга, Татарстан мәдәниятен үстерүгә үзеннән бәһаләп бетергесез өлеш керткән искиткеч шагыйрь, язучы, галим, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе буларак күңелләребезгә кереп калды. Аның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә саклаnыр.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы коллективы, танылган язучы, халык шагыйре, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйль улы
вафатына бәйле рәвештә, туганнарының һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.
Олы йөрәкле шәхеснең рухы тыныч, туфрагы җиңел булсын. Сезгә сабырлык һәм түземлек телибез. Разил Исмәгыйль улының якты истәлеге безнең йөрәкләрдә озак еллар саклаnыр.

«Татнефть» компаниясе администрациясе һәм профсоюз комитеты, Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге ТР Дәүләт премиясе лауреаты, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйль улының
үлеме сәбәпле, тирән кайгы кичерә, аның туганнарының һәм якыннарының олы кайгысы ачысын уртаклаша.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, танылган язучы, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре, театрыбызның якын дусты
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйль улының
вафат булуы сәбәпле, туганнарының һәм дусларының тирән кайгыларын уртаклаша. Театрыбызга һәрдаим ярдәм итеп, аның үсешенә зур өлеш керткән якын дустыбыз, тугры тамашачыбыз Разил Вәлиевнең якты истәлеге күңелләребездә мәңге саклаnыр!

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының элекке депутаты, Татарстан Республикасы мәдәният һәм җәмәгать эшлеклесе
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйль улының
вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Мәрхүмнең урыны җәннәттә булсын, якыннарына сабырлык һәм ныклык бирсен.

Вәлиев Разил Исмәгыйль улының вафаты сәбәпле, туганнарының һәм якыннарының кайгысын ихлас күңелдән уртаклашабыз.
Милли китапханә директоры булып эшләгән елларында аның дәрәҗәсен күтәрүгә керткән зур өлеше һәм коллективта татар халкының теленә һәм мәдәниятенә карата зур ихтирам булдыруы өчен без Разил Исмәгыйль улына бик рәхмәтлебез.
Разил Исмәгыйль улы үзенең «китапханәчеләр «юк» дип әйтмәскә тиеш» дигән киңәше һәм «…акны кара дип сөйләмәм» дигән шигъри юллары белән мәңге хәтеребездә саклаnачак.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе коллективы

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Әбиебезгә – 100!

Мин – аның оныгы. Табигатьтә алтын көз хакимлек иткән чорда Азнакай районының куәтле авылында дөньяга аваз сала ул. Таһирә дип исем кушалар. Әтисе – Бари, әнисе – Гыйлемзадә. «Мин кечкенәдән үк шук, шаян булып үстем, әмма белемгә омтылышым көчле иде», – дип хәтер яңарта ул. Шуңа да мөгаллимлек һөнәрен сайлагандыр инде.

Әби белән сөйләшеп утырганда аның яхшы хәтеренә, тормыш вакыйгаларын эзлекле, мәгънәле итеп тәмләп сөйләвенә дә сокланмый мөмкин түгел. Бала чагында күпбалалы гаиләдә тәрбияләнеп үскән, күпне кичергән әбием сабыр гына, тыныч кына хәтер сандыгын чишкәндә, әйтерсең лә матур китап укыйсың. Бөек Ватан сугышын боегып кына искә ала. Галимҗан бабай белән гаилә корып, алар бер кыз, өч ир бала тәрбияләп үстергәннәр, аларга яхшы үрнәк булганнар. Нинди авыр вакытларда да мал асрап гомер иткәннәр. «Шуның аркасында ач-ялангач булмадык», – ди әбием.

Әбиемнең күңел матурлыгын, йөз аклыгын һәм, әлбәттә, тырышлыгын тормыш авырлыклары җимерә алмаган. Ул гомер-гомергә тормышны яраткан. Янәшә-тирәдәгеләргә яхшы мөнәсәбәттә, изге ниятә булган. «Мине менә шулар озын гомерле итте дә», – дип әйтүе дә юкка гына түгел.

Бу көннәрдә әбиемә 100 яшь тула. Хәзерге көндә ул Азнакай районының Түбән Яке авылында, барча туганнарыбызны, безне – тугыз оныгын, егерме оныкчыгын шатландырып гомер итә. Без исә саулык-сәламәтлек, бәрәкәтле картлык телибез.

Айнур МОСТАФИН

БҮРЕК

Әти яңа мыек калкытканнан алып тракторын да, авыр йөк машинасын да, автобусын да йөртте. Хезмәт стажы 46 елга җыелды. Армиягә озатумы, килен төшерүме, үлем-җитем булсынмы – колхоздан автобус җибәрәләр иде бит. Менә шунда әтинең әйткән сүзләре истә калган: «Беренче чиратта шоферларны хөрмәт итеп, ашатырга кирәк. Алар кеше гомере өчен җавап бирә, күңеле көр булганда, исән-имин йөриләр».

Юлдан соң гына кайтыр иде. Безнең гадәткә кергән: әти кайтканын көтеп кенә торабыз. Машина тавышы ишетелде исә, көн димисең, төн димисең, җәй димисең, кыш димисең, ялт кына өскә берәр нәрсә эләсең дә, ашыгып, капка ачарга йөгерәсең. Әтинең күзләре яктырып китә!

Бер мәлне әти Краснодарга чыгып китте. Ул вакытта хәзерге кебек телефон юк бит инде, хәбәрләшеп булмый. Кайчан кайтасын да белмибез. Кышкы караңгы төн. Бар тереклек беткән, яктылык сүнгән кебек. Мин, тырыша-тырыша, немец телен үзләштереп утырам. Бөтен йорт тирән йокыда. Кинәт, төнге тынлыкны ертып, әтинең машина тавышы ишетелде. Чыгып йөгердем. Бәхет эше инде. Ул чакта затлы нәрсә сирәк эләгә бит. Әти Краснодарда куян тиресеннән искиткеч матур ак бүрек сатып алган да: «Миңа капка ачкан кызга була», – дип нәзер әйтеп куйган. Әйткән сүз – аткан ук. Ул гаҗәп матур бүрек миңа эләкте. Бик яратып кидем аны!

Җидесендә ни булса, җитмешендә шул булыр, диләр бит. Сүздә торырга, гаделлеккә өйрәтте безне әти. Яратып-сөеп, аталарча кайгыртып үстерде ул балаларын.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА

goodfon.ru

Көз

Алтын-сары
Яфракларны
Җилләр сыный.
Иртә-кичен
Суык бабай
Бармак яный.
– Ник гомергә
килми икән
шушы язлар?! –
Дигән кебек,
Моңсу гына
Китә казлар.

Әнә инде
Юлга чыккан
Торналар да...
Бер үк сүзне
Кабатлыйлар
Гүя бар да:
– Суык бабай
Арттан җитеп
Харап булмыйк,
Оча торыйк,
Тор-рыйк, тор-рыйк!

Хәкимҗан ХАЛИКОВ

«ВТ» архивыннан

ЗИННУРЫБЫЗ!

Халкыбызда «Кайгы агач башыннан түгел, адәм башыннан йөри» дигән әйтем бар. Менә шул мәлдә сынмау бик мөһим. Татарстанның халык артисты Зиннур Нурмөхәммәтов нәкъ менә сынмаучылар рәтенә керә, тормыш исә аңа кайгы-хәсрәтне балачагыннан ук мулдан бирә.

1945 елда Исмаил бабасы белән әнисе Мәрьямне кулга алалар. Анык кына сәбәбе әле хәзер дә мәгълүм түгел. Бабасының сәүдә эшенә хирыс булуы сәбәп булгандыр дип фаразлана. Исмаил бабай сөргеннән әйләнеп кайтмый, укытучы булып эшләгән әнисе исә кайта, әмма... Тормыш иптәше аннан ваз кичеп өлгергән була инде. Янәсе, чын коммунист кулга алынган хатын белән гомер итәргә тиеш түгел. Әнисе бу хәлне бик авыр кабул итә, бераздан икенче берәү белән гаилә корып җибәрәләр. Бераздан туган-тумачалар белән берничә гаилә җыелып, балаларын да алып, Әстерханнан Сахалинга, Орловка авылына күченеп китәләр. Зиннур Орловкадан алты чакрымдагы шәһәрнең рус мәктәбенә йөреп укый. Иртән алты чакрым шәһәргә, аннан алты чакрым авылга. Бала өчен бик авыр инде бу. Зиннурны шәһәрдәге балалар йортына урнаштыралар. Аның белемгә тартылуы ифрат көчле була. Шул ук вакытта татар баласы булуын да онытмый. Күңел төпкелендә милли хисләр әледән-әле баш калкыта, татар җырларын, татарча сөйләшкәннәрен тыңларга бик ярата ул. Горнозаводск шахталарында эшләүче татарлар исә әледән-әле очрап тора. Урамда туктап, Рәшит Ваһапов пластинкаларын тыңлап торган вакытлары да була. Әнисе дә улының җырга хирыслыгын бик хуплый һәм бик матур җырлый торган була. Зиннур иң беренче итеп «Урман кызы»н өйрәнә.

Гаилә архивыннан

Зиннурның иҗат юлы менә шушы кечкенә чишмәдән башлана. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Владивосток шәһәрендә урман эшкәртү заводына эшкә урнаша. Аннан шундагы музыка училищесына укырга керә. Армиядә, Тын океан флотының җыр-бию ансамблендә җырчы буларак хезмәт итә. Хәрби хезмәтен тутыргач, әнисе аңа Казанга барырга, җырлавын камилләштерергә, татар җырларын яхшылап өйрәнергә киңәш итә.

Бу хәл Зиннурга чын-чынлап канат куя. Менә ул диңгезче киемендә Казан урамнарын айкый, консерватория ишеген шакый. Консерваториядә җырлавын мактыйлар, әмма бу уку йортында опера җырчылары әзерлиләр, ә опера җырлау өчен озын буйлы булу кирәк икән. Зиннур туган ягы Әстерханга кайтып китә, шунда кинофикация оркестрында җырчы булып эшли башлый. Бәхетенә, Казанга гастрольгә китәләр. Шунда аны филармониянең сәнгать җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов абайлап ала һәм Казанга эшкә чакыра. Берникадәр вакыттан соң Мәскәүгә, Бөтенсоюз эстрада сәнгате иҗат мастерскоена, Георгий Виноградов классына укырга җибәрәләр. Рабига Сибгатуллина, Римма Ибраһимова, Клара Хәйретдинова, Виктор Шәрәфетдинов та шул төркемдә. Мәскәүдә укыганда, ул, конкурсларда катнашып, җиңү арты җиңү яулый. Зиннурның соңгы эш урыны – Г. Тукай исемендәге дәүләт филармониясе. Мин дә шунда оригиналь жанрда эшләдем, Зиннур белән гаилә корып җибәрүебезне тормышымдагы иң бәхетле чагым дип исәплим. Үзара аңлашып, бер-беребезне хөрмәт итеп гомер кичердек. Мин үзем рус милләтеннән, татарча аралашуымны да мактыйлар. «Зиннурга кияүгә чыгасыңны алдан белгәнсең, шуңа татарчаң әйбәт инде», – дияләр иде миңа. Зиннур – татар җыр сәнгатенә җиңелчә генә бию алымнары да керткән җырчы әле ул. Зиннурыбыз филармониядә 30 ел эшләү дәверендә халыкның тирән ихтирамын яулады, «Татарстанның халык артисты» исеменә лаек булды.

Зиннурыбызның бакыйлыкка күчүенә дә быел октябрь аенда егерме ел булды. Сагынабыз, юксынабыз, аны хәтердә яңартмаган көнебез юк. Каберенә дә эз суынмый, Иске Татар бистәсе зиратында Тукай белән янәшәдә җирләнде ул. Мәчеттә Коръән укыттык, каберен гел чистартып, төзекләндереп торабыз. Җирләнгән көнендә иртән иртүк зиратта идек. Иртән җил-давыл күзәтелде, яңгыр сибәләде, озак та үтмәде, көн тынычланды, күктә болытлар таралды, кояш елмайды, бу халәткә тирән мәгънә салынган иде кебек. Тыныч йокла, мөхтәрәмебез, Зиннурыбыз!

Татьяна РОМАНОВА

«ХЫЯНӘТ КАВЫШТЫРДЫ»

Мин аны һич уйламаганда-көтмәгәндә очраттым. Әйләнә-тирәне күзәтә-күзәтә, тукталышта автобус көтеп торам. Шулчак кемдер иңемә кагылгандай булды. Борылып карадым. Каршымда басып торган шактый олы яшьләрдәге ханым миңа елмаеп сәлам бирде. Исәнләштем, әмма танымадым. «Танымыйм», – дидем. «Танымыйсыздыр шул инде, – диде ул, уңайсызлангандай итеп. – Гомер көзендә адәм баласының бер көне – бер гомер, диләрме әле...» Сөйләшеп киттек тә, автобус килгәнне дә, вакытны да онытып, якында гына урнашкан бакчага таба юл алдык. Нәкъ элеккечә... Ул чагында да безнең аның белән сөйләшеп, серләшеп сүз бетмәде. Аратирә ул күз яшьләренә буыла-буыла елап та алгалады. Үкенде дә... Ләкин ни мәгънә? «Мин аны шундый яраттым. Ә ул...» Аның күңелне тетрәтеп куйган шушы сүзләре җитә миңа. Барысы да искә төшә, барысы да бүгенгедәй күз алдына килеп баса. Әнә ул институтка ашыга. Лекция башланырга берничә минут калып бара. Ул йөгерә-йөгерә баскычтан күтәрелә башлый. Шунда аягы таеп китеп, чак кына егылмый кала. Егылыр иде инде. Артыннан менеп килүче егет аны кочагына ала. Һәм төпсез диңгездәй зәңгәр күзләрен кызга текәп: «Кая шултикле ашыгасың, туташ?» – ди дә әсирлектә телсез калган кызны бер мизгелдә ташкын булып урап алган хисләре белән ялгыз калдырып, китеп тә бара. «Сукырларча яраттым...» – дияр ул соңыннан, дистә еллар узып, аның белән булган көннәрнең бөтен ачысын татып караганнан соң.

Егетне күргән шул минуттан, шул мизгелдән үзгәрә дә куя ул. «Бер күрүдә гашыйк булдым», – дигән сүзләргә көлеп кенә караган кыз башын югалта. Шул көннән аның кара зур күзләре егетне эзли. Һәм... көннәрдән бер көнне ул аны очрата. Һәм шуннан соң инде алар аерылмыйлар. Аз гына йөриләр дә өйләнешәләр. Кыз чиксез бәхетле, карап торышка егет тә бәхетле сыман. Тик нигәдер ул беркайчан да хатынына «яратам» дигән сүзне ялгыш та ычкындырмый. Ә бер-бер артлы ике малае тугач, өйгә дә соңлап кына кайта башлый. Кая инде... эше күп ич аның. Гаиләне туендырырга кирәк ич аңа. Тезенә бер генә мәртәбә дә утыртып сөймәгән балалары да торa-бара әтиләреннән читләшә. Хәер, әти кешенең бу хәлләргә исе китми. «Бәйләнмәгез миңа, арыдым», – дип әйтүдән туйды ич инде ул. «Миңа танышларым: «Иреңне чит хатын белән күрдек», – дигәч, ышанмадым», – ди ул, янә шул вакытларга әйләнеп кайтып. Ә бервакыт аның ире ялга, көньякка оча. Хатынының: «Минем дә барасым килә», – диюенә: «Ә балаларыңны кемгә калдырасың?» – дип кенә куя. Ире ялда чагында, урамда аны таныш булмаган бер хатын туктата. «Иреңнең ялга кем белән киткәнен беләсеңме? – дип сорый һәм шундук җавабын да бирә: – Җитәкчесе белән, йөремсәк хатын ул. Ике мәртәбә кияүгә чыкты инде». Хатын хәзер янә «җитәкче»нең ире белән танышуы, икесенең бергә аэропортка аларны каршы алырга баруы һәм моңа үз күзләре белән ышануы хакында, инде моңа дистәләгән еллар үтсә дә, елый-елый сөйләп ала.

Шуннан соңмы? Шуннан соң алар аерылыша. Ир шулкадәрле битараф бәндә булып чыга ки, бер генә мәртәбә дә балаларының хәлен белешми, ничек яшәүләре белән кызыксынмый. Шул көннән алар ике бәхетсез, ике ялгызак очраша башлыйлар. «Онытасым юк, мең рәхмәт аңа, – ди хатын, сүзен дәвам итеп. – Авыр чагында ул миңа терәк булды, әйе, ул да хатынын ярата иде. Нишләтәсең, язмыш шаяруыдыр. Без кушылдык, кирәк чагында бер-беребезгә таяныч була белдек. Ул балалар өчен дә яхшы әти иде. Без аның белән өч дистә елга якын бергә булдык. Хәзер ул юк инде. Әйбәт кеше иде». Иң мөһиме, хатынның әйтүенә караганда, үзен яраттыра алган ул.

Әңгәмәдәшем ташлап киткән иренең «теге хатын» белән озак яшәмәвен, биш ел да тормыйча, икесенең ике якка каерылуын, гаҗәпләнеп димим, күңеленнән һаман китә алмаган үпкә-рәнҗү белән искә ала. Ни дип әйтәсең инде монда? Чиләгенә күрә капкачы... Бүрене ничек кенә ашатма, барыбер урманга карый, диләр бит... Болар да шулай. «Инде өченче мәртәбә өйләнгән, дип ишеттем. Эчүгә дә сабышкан, имеш. Теләсә нишләсен. Мине кадерләп, минем турында кайгыртып торган бер генә ир бар иде бу дөньяда. Ул да юк инде...» – дигән иде ул хушлашканда.

Адәм баласы кылган һәр гамәл – яхшымы ул, яманмы – кире үзенә әйләнеп кайта. Бу хәлләрне искә төшерәсең дә моның шулай булуына тагын һәм тагын бер кат инанасың.

Мәдинә АВЗАЛОВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы эшен дәвам итү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы эшен 2023 елның 2 ноябрендә дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 19 октябре, № 2202-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык сигезенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кырык сигезенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 489-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
2. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 492-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
3. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 493-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзалары – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 482-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 484-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 481-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы вәкиллекләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 494-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 15 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында сәнгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 464-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
9. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 478-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 483-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясының үз көчен югалтуын тану хакында» 458-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
12. «Гражданнарның гаражларга һәм алар урнашкан җир кишәрлекләренә хокуклар алуына бәйле аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 480-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 135^4 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 433-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 474-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 479-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
17. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан вазыйфага сайлана яисә билгеләп куела торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның таныклыклары турында.
18. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
19. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 24 статьясына һәм «Альтернатив граждан хезмәте турында» Федераль законның 4 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
20. Хәсәнов Рөстәм Ринат улының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында.
21. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты составына үзгәреш кертү турында.
22. «Россия Федерациясе Граждан кодексының дүртенче өлешенә (хокук ияләре билгесез авторлык хокукларының һәм уртак хокукларның аерым объектларыннан файдалану тәртибен билгеләү өлешендә) үзгәрешләр кертү турында» 411043-8 номерлы федераль закон проекты хакында.
23. «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законының 14 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 441427-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе территориясен чит дәүләтләрдән йогышлы хайван авырулары кертүдән саклау өлешендә).
24. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 410399-8 номерлы федераль закон проекты турында (тулы һәм дөрес экологик мәгълүматны яшереп калган, белә торып бозган яисә үз вакытында хәбәр итмәгән өчен административ җаваплылык чараларын көчәйтү хакында).
25. «Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2006 елның 29 декабрендәге 256-ФЗ номерлы Федераль законның 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 396291-8 номерлы федераль закон проекты турында (сертификат алган затның балигъ булган балаларының, шулай ук иренең сатып алына торган торакта өлеш бирелүдән баш тарту мөмкинлеге турында һәм башка торак урын сатып алган очракта аларга өлешләр бирү бурычларын үзгәртү хакында).
26. «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 333^{33} статьясына үзгәрешләр кертү турында» 441961-8 номерлы федераль закон проекты хакында (дәүләт пошлинасы күләмен үзгәртү өлешендә).
27. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93^3 статьясындагы 2 пунктына үзгәрешләр кертү турында» 398197-8 номерлы федераль закон проекты хакында (муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча һәм муниципаль берәмлек тарафыннан кредит оешмаларыннан алынган кредитлар буенча бурыч йөкләмәләрен каплау өчен муниципаль берәмлек бюджетына Россия Федерациясе субъекты бюджетыннан бирелә торган бюджет кредитлары өлешендә).
28. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 485-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
29. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 486-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
30. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 490-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
31. «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 477-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
32. «Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 487-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
33. 2024 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы проекты турында.
34. Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе эшчәнлеге турында мәгълүмат.
35. Хөкүмәт сәгате: «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне цифрлы форматта күрсәтү турында».
36. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 19 октябре, № 2161-VI ДС

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Чагыштыру кирәкме?

Татар әдәбияты артта калган, диючеләр бар. Кем белән чагыштырганда шулай бу? Гадәттә, рус яки чит ил язучылары белән чагыштыралар.

Менә без эстраданы да шулай чагыштырабыз. Татар җырчылары Америка яки Европадан 20–30 елга артта кала, русныкыннан – 10–15 елга, дип җиппәрәбез. Бөтен нәрсәне дә шулайрак чагыштырабыз. Ник алай эшләргә кирәк? Мин аңлый алмыйм.

Әйтик, менә өч кеше. Беренчесе Вашингтонга оча, барып җитәренә өч сәгать калган, икенчесе ике сәгатьтән Мәскәүдә булачак. Өченчесе Казанга бара. Килеп җитә язган. Менә боларның кайсы алдарак? Әгәр Вашингтон белән чагыштырабыз икән, әлбәттә, беренчесе алда. Калганнарга анда барып җитәргә бик күп вакыт кирәк. Әгәр Мәскәүгә карасак, анда икенче кеше алдарак булачак. Казанга, әлбәттә, өченче кеше беренче килеп җитәчәк. Менә бу кешеләрне нигә чагыштырабыз соң? Аларның юнәлеше дә, максаты да төрлечә бит. Өчесе өч җиргә бара, өч юнәлештә хәрәкәт итә. Казанга барырга чыккан кешегә, әйтик, Мәскәү дә, Вашингтон да кирәкми. Ул үзенең максатына бер сәгатьтән ирешәчәк. Икенче кеше – ике сәгатьтән. Өченчесе – өч сәгатьтән. Шулай булгач, боларның кайсы үз максатына алданрак ирешәчәк? Кайсы алдарак бара?

Әдәбиятны да, сәнгатьне дә чагыштыру белән артык мавыгырга кирәкми. Чабышка чыккан атлар түгел алар. Монда иң мөһиме – әдәбиятның юнәлеше һәм максаты. Ерак китү һәрвакытта да алда баруны аңлатмый. Алда бару да сыйфат билгесе түгел әле.

Алыйк менә эстраданы. Руслар, чынлап та, Америка һәм Европа артыннан куа, шул юнәлештә хәрәкәт итәләр. Тик барыбер фәлән елга артта калып киләләр. Һәм нәрсәгә ирешәләр? Бүгенге рус эстрадасы, үзенең милли йөзен югалтып, Европа, Америка һәм тагын әллә нинди модный стильләрдән торган боламыкка әверелеп беткән. Бүгенге рус эстрадасында үзләренең милли моңына урын юк диярлек. Кадышева бар инде, тагын берничә җырчыдыр. Үз моңыннан китеп, ул нәрсәгә иреште инде? Алга да чыга алмады, дөньяны да яулamaды, бары тик үз йөзен генә югалтты. Безнең эстрада да шул юнәлешкә омтыла. Кирәкме инде ул безгә?

Хәзер әдәбиятны да шул кысага куып кертергә маташалар. Зур дәүләте була торып, хәтта рус та шуңа алдана. Бертуктаусыз рәвештә чит ил язучыларының әсәрләрен пропагандалыйлар. Шуларны культ дәрәҗәсендә күрсәтәләр. Шундый юллар белән танылa алырлык уртакул язучылар русның үзендә дә җитәрлек бит инде югыйсә. Күпкә талантлыраклары да бихисап. Юк, аларны күрмиләр, миллион сумнар түгеп, чит ил язучыларын тәрҗемә итәләр. Джоан Роулинг, Стивен Кинг кебек күп табыш китерә торганнарын аңларга мөмкин инде – акча һәркемгә дә кирәк. Ләкин ыбыр-чыбырлары да мыжгып тора бит. Чит ил әдәбиятын әйбәтрәк итеп күрсәтергә тырышу хәзер Россиядә шул дәрәҗәгә җитте ки, хәтта рус язучылары да чит милләт псевдонимы ала башлады. Шулай иткәч, чынлап та китабыңны күбрәк сатып алалар, комментларны да күбрәк язалар. Монысын тирәннән белеп әйтәм.

Россия халыкларына хас бер сәер үзенчәлек – читләргә табыну, аларның тормыш рәвешен, мәдәниятен өстен итеп күрү.

Бу шаукым татар укучысын да ияртә. Моңа кадәр дә чит милләт мәдәниятенә мөкиббән булып, «Россия күләмендә», «СССР күләмендә» дип бәяләүгә исе китеп, үзенекен санламаска күнеккән халык бит инде. Менә бездә «дөнья әдәбияты»на чыгу турында сөйләнергә яраталар. Нәрсә соң ул – «дөнья әдәбияты»? Безнең дөнья монда бит инде – үз җиребездәге үз укучыларыбыз. Үзебезнең милләт кешеләре. Татар әдәбияты иң беренче чиратта шулар өчен эшли. Ә «дөнья әдәбияты» дигәндә без, телибезме-юкмы, чит дөнья турында сүз алып барабыз, дине дә, көне дә безнекенә охшамаган чит халыклар әдәбиятына чыгу турында хыялланабыз. Кызыктыргыч кебек инде бу. Данлы гамәл сыман тоела... Һәм чит гүзәлләрнең матурлыгына кызыгып, үз хатынын назламый, гаиләсен карамый торган ирне хәтерләтә. Ә гүзәлләр ахмак түгел – үз хатынын да канәгатьлектә яшәтә алмаган иргә берсененң дә исе китми. Әдәбият та шулай. Бөтен дөньяны шаккатырырдан алда, әдәбият үз халкының мәхәббәтен яулый алырга тиеш.

Аны башка халыкларныкы белән чагыштыру үз иреңне бүтән ирләр белән чагыштыру шикелле. Әйе, бәлки, кимчелекләре дә бардыр, тик ул бит синең белән яши. Ул синең янында: терәгең-таянычың булып, ихтыяҗларыңны канәгатьләндерергә тырышып яши. Башка хатын белән яшәсә, бәлки, ул ир дә бүтән төрлерәк булыр иде. Әлегедән әйбәтрәк булса, бәлки, ул сиңа тәтемәгән дә булыр иде... Бу чагыштыру күз алдына китерергә җайлырак булсын өчен генә. Ахыр чиктә, һәр гаилә – дәүләтнең, милләтнең кечкенә моделе бит инде.

Әдәбият үз халкыннан ерак китә алмый... Халкы нинди, әдәбияты да, сәнгате дә шундыйрак була. Дәүләте көчле халыкларның әдәбияты үтемлерәк: алар хәтта уртакул әсәрләрне дә шедевр дип тәкъдим итәргә һәм шуңа ышандырырга сәләтле.

СИН ИКӘНСЕҢ, ТОРМЫШ, ИСӘНМЕ!

«ТАТНЕФТЬ»НЕҢ САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВА ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯСЕН КЕМНӘР АЛДЫ?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Әскәр Маликов

Бу көннәрдә Татарстанның Милли китапханә сәхнәсе шигъри моңга күмелде. Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияне быел беренче тапкыр Казанда тапшырдылар. Моңа кадәр ул Әлмәт шәһәрендә уза иде. Тантананы үткәрү урынын Казанга күчерүләре юкка гына түгел. Быел – Татарстан өчен дә, «Татнефть» компаниясе өчен дә зур юбилейлар елы. Татарстанда нефть ятмалары эшкәртелә башлауга – 80 ел, дөньядагы иң зур нефть ятмаларының берсе булган Ромашкино ятмасыннан нефть фонтаны бәреп чыгуга 75 ел тулды. Быелгы тантана да әнә шул бәйрәм программасы кысасында узды.

Башкортстан якларында туып-үссә дә, Саҗидә Сөләймановaның гомере Әлмәттә узган, кабатланмас әсәрләре дә нәкъ менә нефть каласында иҗат ителгән. Шуңа да әлмәтлеләр аны якын итеп, үзебезнеке дип атый. Шәһәрдә бөек шагыйрәнең исемен мәңгеләштерүгә зур игътибар бирелә. Бүген нефть каласындагы бер урам белән китапханә аның исемен йөртә. 2006 елдан исә «Татнефть» компаниясе һәм Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан Әлмәттә Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия тапшырыла башлый.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла яшерми: башлаганда әлеге премия шундый зур колач алыр дип күз алдына да китермәгәннәр.

– Олы шагыйрәбезнең исемен шулай мәңгеләштерү фәрештәләрнең «амин» дигән чагына туры килгәндер. Булмаганны күтәреп булмый. Саҗидә апаның шигырьләре – татар исән чагында татар күңелендә мәңге яши торган шигырьләр. Андый кешенең исемен байрак итеп күтәрсәң дә горурлык, – ди әдип.

Гомер буе каләм чарлаган шагыйрь өчен иҗатының үзеннән соң да сүнмәве – зур бәхет. Саҗидә Сөләйманова да әнә шул бик сирәк бәхетлеләр рәтендә. Дәрәҗәле премияне унҗиде ел рәттән нәкъ менә октябрь аенда тапшырып килүләре дә юкка түгел. Быел 3 октябрьдә Саҗидә Сөләймановага 97 яшь тулган булыр иде. Шул рәвешле күренекле шагыйрәнең туган көне ел саен үзенә күрә бер шигырь бәйрәменә әйләнә. Быел да сәхнәдән шагыйрәнең үлмәс шигырьләре, алар көйгә салынган җырлар яңгырады. Фойеда Саҗидә Сөләймановaның 1963 елдан бирле дөнья күргән китаплары урын алган, шунда ук шагыйрьләр өчен «ирекле микрофон» булдырылган иде.

«Татнефть» компаниясе генераль директоры урынбасары, «Татнефть»нең хәйрия фонды рәисе урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев фикеренчә, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премиянең дәрәҗәсе дә елдан-ел арта бара.

– Премия ияләрен билгеләү елдан-ел авырлаша. Чөнки аңа дәгъва кылучылар күп һәм барысы да – әлеге бүләккә лаек шәхесләр. Бу Саҗидә Сөләйманова исемендәге бүләкнең дәрәҗәсе хакында сөйли, – ди ул.

Әлеге премия ел саен өч өлешкә бүлеп тапшырыла. Жюри иң яхшы дип тапкан 6 кешегә (3 төп премия, 3 кызыксындыру премиясе) премия бирелә, әдәбият өлкәсенә яңа аяк басучы 10 студентка исә ел буе стипендия түләнә. Быел төп премиянең күләме дә 150 мең сумга җиткерелгән. Кызыксындыру бүләгенә лаек булган каләм тибрәтүчеләрнең һәркайсына исә 75 мең сум күләмендә премия тапшырдылар.

Быел Саҗидә Сөләйманова исемендәге төп премиягә лаек булучылар арасында танылган шагыйрә Йолдыз Шәрәпова да бар. Бүген аның 20 китабы дөнья күргән. Саҗидә Сөләйманова исемендәге премиягә исә балалар өчен язылган «Китаплы кич» шигырьләр җыентыгы өчен лаек булган ул. «Саҗидә апаны безгә әле ачасы да ачасы. Аның шигырьләре Коръән кебек. Шундый тирән алар», – ди шагыйрә.

Дөрестән дә, Саҗидә Сөләйманова шигырьләренең һәр юлында һәркем күңеленә салып, үз язмышы аша кичерә торган хис-тойгы, вакыйгалар урын алган. Бигрәк тә гүзәл затларга аваздаш алар. Шуңа булса кирәк, шагыйрә исемендәге премия ияләренең дә күпчелеген хатын-кызлар тәшкил итә.

Чаллыда яшәп итүче яшь шагыйрә, Белла халыкара премиясе лауреаты Лилия Гыйбадуллина – Саҗидә Сөләйманова исемендәге иң беренче премиягә лаек булучыларның берсе. Премия әле яңа тапшырыла гына башлаган елны КДУда 1 нче курста укыган чагы була аның.

– Саҗидә Сөләймановaның иҗаты һәм аның исеме минем белән гел янәшә бара. Саҗидә апаның иҗаты – гомер узган саен кайтып укый торган шигърият. Гомернең кайсы чорында да актуальлеген югалтмый. Чөнки ул –кеше тормышы, кеше күңеле турындагы олы шигърият, – ди шагыйрә.

Кабатланмас әсәрләре белән халык күңелен яулаган шагыйрә Саҗидә Сөләймановaның иҗаты киләчәктә дә кайта-кайта өйрәнелер әле. Оештыручылар аның исемен мәңгеләштерүгә зур өлеш керткән премияне дә камилләштерергә җыена. Киләчәктә премияләр ел саен түгел, ә ике елга бер тапкыр биреләчәк. Аның акчалата кыйммәте дә шактый артачак, дип ышандыралар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Фикер

Марат ӘХМӘТОВ, Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе:

– Саҗидә Сөләйманова исемендәге премия кебек чаралар ярдәмендә иҗат әһелләре каләм осталыгы аша укучыны телнең матурлыгына тартып кертә алабыз икән, димәк, без телебезне саклыйбыз дигән сүз. Бирелә алар җиңүчеләрне билгеләп кенә калмыйлар. Яшь каләм ияләренә үсеп китү өчен махсус стипендияләр булдырып, аларны куәтләп, үстереп тә торалар. Гомумән, «Татнефть» никадәр колачлы, игелекле гамәлләр башкара. Компаниянең хәйрия фондының «Рухият» программасы үзе генә дә никадәр социаль проектларны тормышка ашыра. Саҗидә апа Сөләйманова исемендәге премия тапшыру тантанасының Казанга күчүе – ул әле безнең башкалабыз өчен дә матур үрнәк. «Татнефть»тән үрнәк алып, үз программаларын булдырырдай җитәкчеләр кирәк. Халкыбызның киләчәген без милли рухыбызны баета барып кына саклый алабыз. Бу эшләребез дәвамлы булсын.

2023 елгы Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия ияләре

Лауреатлар

✓Алена Кәримова (Казан) – татар теленнән рус теленә тәрҗемә ителгән «Птица сердца» шигырьләр җыентыгы («Яз» нәшрияты, 2022) өчен;

✓Йолдыз Шәрәпова (Казан) – балалар өчен язылган «Сәяхәтче чемодан» – «Китаплы кич» шигырьләр җыентыгы (Татарстан китап нәшрияты, 2018) өчен;

✓Минзифа Әхмәтшина (Әлмәт) – «Иңнәремдә ак җилкән» шигырьләр җыентыгы («Рухият» нәшрияты, 2019) өчен.

Кызыксындыру бүләге

✓Гөлнур Айзатуллова (Буа) – «Баллы кирпеч» повестьлар һәм тарихи хикәяләр җыентыгы («Идел-Пресс», 2022) өчен;

✓Илдус Диндаров (Нурлат) – «Торна күзе» повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы (Татарстан китап нәшрияты, 2020) өчен;

✓Ольга Овчинникова (Казан) – балалар өчен «Зеленый ёж» дип аталган шигырьләр һәм әкиятләр җыентыгы («Плутон» нәшрияты, 2022) өчен.

Стипендиатлар

✓ Руфия Мортазина – А.М. Горький исемендәге Әдәбият институтының (Мәскәү) сәнгатьчә тәрҗемә кафедрасы;

✓ Илмир Газизов – А.М. Горький исемендәге Әдәбият институтының (Мәскәү) сәнгатьчә тәрҗемә кафедрасы;

✓ Алинә Закирова – Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты;

✓ Ландыш Гобәйдуллина – Казан федераль университетының Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм массакүләм коммуникацияләр институты;

✓ Дарина Мороз – Әлмәт дәүләт нефть институты;

✓ Екатерина Мершина – Әлмәт дәүләт нефть институты;

✓ Виктория Обручникова – Түбән Кама педагогика көллияте;

✓ Полина Валова – Әлмәт политехникумы;

✓ Алинә Гыймадиева – Әлмәт медицина көллияте;

✓ Полина Яковлева – Чаллы дәүләт педагогика университеты.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5146 данә
Гомуми тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 344

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+